ЖОМГА
5 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 4 (5804)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

ПОЛИТИК-АГАРТУ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ КАДРЛАРЫНА ИГТИБАРНЫ КӨЧӘЙТИК

ВКП(б) нын XVIII нче съезды алда торган бөек бурычларның берсе итеп, хезмәт ияләрен коммунизм рухында тәрбияләү мәсьәләсен куйды. „...Калган барлык бурычларны хәл итү,—киң мәгнәсендә коммунистик тәрбия бирүнен, хезмәт ияләренең бөтен массасын һәм бөтен совет интеллигенциясен чолгап алган коммунистик тәрбия бирүнең уңышларына, барыннан да элек, безнең бу өлкәдәге уңышларыбызга бәйләнгән“ (Молотов).

Бу бөек һәм мактаулы эшне— хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләү эшен уңышлы хәл итүдә партия, совет, комсомол һәм профсоюз оешмалары белән бер рәттән, политик-агарту учреждениеләренә гаят зур җаваплылык йөкләнә. Безнең күп санлы клубларыбыз, уку өйләребез, көтепханәләребез һәм кызыл почмакларыбыз үзләренең эшләрен шулай итеп оештырырга тиешләр ки, алар хезмәт ияләренең көннән-көн үсеп барган политик һәм культура сорауларын тулы канәгатьләндерерлек булсыннар, массада социалистик милеккә, хезмәткә коммунистик мөнасәбәт тәрбияләүгә хезмәт итсеннәр. Бу гаят зур җаваплы эшне бары тик тиешле кадрлар белән, Ленин—Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгән, политик хәзерлекле һәм культуралы работниклар белән тәэмин ителгән клублар, уку өйләре, көтепханәләр һәм кызыл почмаклар гына уңышлы башкарып чыга алалар.

Безнең республикабызда андый работниклар аз түгел һәм алар җитәкчелегендә эшли торган культура учреждениеләрендә эш чын магнәсе белән яхшы куелган, хезмәт ияләренең политик белем дәрәҗәләрен һәм культураларын үстерүгә ярдәм итәрлек итеп оештырылган. Мәсәлән, иптәш Нургалиев мөдир булып эшли торган Чүри-Бураш уку өендә (Апас районы) 1939 нчы елның 11 ае эчендә төрле темаларда 20 тапкыр доклад тыңланган, 350 тапкыр газеталар һәм журналлар уку үткәрелгән, 13 тапкыр спектакль куелган, 3 тапкыр концерт, 9 тапкыр кичә оештырылган һәм 10 тапкыр кино-картина күрсәтелгән. Уку өе яхшы итеп җиһазландырылган, матур итеп бизәлгән, чиста, җылы һәм якты. Колхозчылар бу уку өенә бик зур кызыксыну белән йөриләр һәм анда үзләренең политик белем дәрәҗәләрен, культураларын күтәрәләр.

Тәтеш районында иптәш Нигматуллин мөдир булып эшли торган Олы Торма уку өе янындагы түгәрәкләрдә 1939 нчы елны 42 кеше ПВХО, 7 кеше „Ворошиловча атучы“, 33 кеше ГСО һәм 5 кеше ГТО значокларына нормалар тапшырдылар. Бу авылда төрле оборона значоклары алган кешеләрнең саны 150 дән арта.

Үзләренең эшләрен хезмәт ияләренең үсеп бара торган политик һәм культура сораулары югарылыгына куйган мондый уку өйләрен һәм колхоз клубларын Татарстанда күп кенә күрсәтергә мөмкин.

Ләкин барлык мәгариф бүлекләре дә һәм ВКП(б) райкомнары да политик-агарту учреждениеләрен җитәрлек хәзерлекле, ул эшне сөюче работниклар белән ныгыткаңнар дип, аларны тәрбияләү, үстерү эше белән тиешенчә шөгыльләнәләр дип әйтеп булмый әле. Моны политик-агарту работникларының составы турындагы маглүматлардан да ачык күреп була. Мәсәлән, уку өе һәм колхоз клубы мөдирләре булып эшләүче 1.676 кешенең 4,3 проценты гына урта мәктәп тәмамлаган, ә 43,4 процентының хәзерлекләре бары тик башлангыч мәктәпнең 4 нче классы күләмендә генә санала. Барлык работникларның 57,3 проценты мөдир булып беренче ел гына эшлиләр. Шуңа да карамастан, РСФСР Наркомпросы янында яшәп килә торган еллык курсларда читтән торып укуга аларның күпчелеге тартылмаган. Укуга тартылучылар өчен дә семинарлар 26 районда гына системалы рәвештә үткәрелә. Калган районнарда ул очраклы рәвештә генә үткәрелә яки бөтенләй үткәрелми. Мәсәлән, Минзәлә һәм Бөгелмә районнарында (РОНО мөдирләре Маликов һәм Штеенников иптәшләр) семинарлар үткәрелмәү генә түгел, Наркомпростан алынган лекцияләр дә күп вакытта урыннарга җибәрелмиләр.

Күп кенә районнарда политик-агарту работникларына район мәгариф бүлекләренең һәм ВКП(б) райкомнарының ярдәме, ул работникларның киңәшмәләрен җыюдан һәм наказлар бирүдән узмый. Алдынгы уку өе, колхоз клубы мөдирләренең эш тәҗрибәләрен уртаклашу оештырылмый.

Байтак кына районнарда уку өе һәм колхоз клубы мөдирләренә уңайлы эш һәм тормыш шартлары тудыру турында кайгыртучанлык күрсәтү һич тә җитәрлек түгел. Колхоз җитәкчеләре клубларны җиһазлау, яктырту, җылыту турында тиешенчә кайгыртмыйлар. Политик-агарту работникларына мондый игтибарсыз караш хөкем сөргән районнарда уку өе мөдирләре еш кына икенче эшләргә күчәргә мәҗбүр булалар. Бу хәл уку өйләрен һәм колхоз клубларын җитәрлек хәзерлекле работниклар белән ныгытуга һәм бу эштә работникларның тәҗрибәләрен баетуга комачаулык итә.

Район мәгариф бүлекләре, ВКП(б) райкомнары, уку өе һәм колхоз клубы мөдирләренә икенче дәрәҗәдәге работниклар итеп карау фактларын тамрыннан бетерергә тиешләр. Ул работникларның политик белем дәрәҗәләрен күтәрүгә, эш тәҗрибәләрен баетуга һәм эш шартларын яхшыртуга зур игтибар бирелергә тиеш. Барлык культура учреждениеләре дә җитәрлек хәзерлекле һәм Ленин—Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгән работниклар белән ныгытылырга тиеш.

Уку өйләре, колхоз клублары, көтепханәләр һәм кызыл почмаклар массаны политик тәрбияләү һәм культура үзәге булып әверелергә тиешләр.

МОСКВАНЫҢ ИНСТРУМЕНТАЛЬ ЗАВОДЫ КОЛЛЕКТИВЫ ЧАКРУЫНА КУШЫЛАЛАР

ТАГЫН ДА ЯХШЫРАК ЭШЛӘРБЕЗ

3 нче гыйнварда кичке сменада „Красный путь“ заводының барлык цехларында җыелышлар үткәрелде. Гаят зур күтәренкелек белән үткән җыелышларда Москваның инструменталь заводы коллективының мөраҗәгате тикшерелде. Җыелышка катнашучылар бу мөрәҗәгатне күтәренкелек белән каршыладылар һәм хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү өчен эшлекле тәкдимнәр ясадылар.

Цех начальнигы иптәш Латыйпов болай диде:

— Безнең цех коллективы үткән елның декабрь ае планын срогыннан алда үтәде һәм планнан тыш 5 станин эшләп чыгарды. Чуен кою буенча да задание арттырып үтәлде. План буенча билгеләнгән 51 тонна урнына 60 тонна чуен койдык. Цехның алдынгы стахановчыларыннан Халиков һәм Шәмсиев иптәшләр заданиене 227 процент итеп үтәделәр.

Цех коллективы 1940 нчы елда тагын да яхшырак эшләү өчен гыйнвар аенда планнан тыш 5 станин эшләп чыгарырга булды. Социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәтенә җитәкчелек итүне кискен рәвештә яхшыртырга, детальләр кою һәм формалау буенча технология процессларын яхшырту буенча конкрет йөкләмәләр алды. Һәм заводның барлык цехларын социалистик ярышка чакырды.

1 НЧЕ ТЕГҮ ФАБРИКАСЫНДА

Фабриканың алдынгы мастерлары һәм стахановчылары яңа елның беренче көннәрендә заданиене арттырып үтәп, хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүдә яңа уңышларга ирештеләр. Беренче номерлы цех коллективы 2 нче гыйнварда заданиене 121 процент үтәде. Цехның алдынгы стахановчылары бу көнне нормаңы 107—115 процент итеп үтәделәр. 3 нче гыйнварда мастерлардан Садыйкова, Александрова һәм Аюшина иптәшләр аеруча яхшы эшләделәр. Алар көнлек заданиене 111—117 процент итеп үтәделәр.

6 НЧЫ ТЕГҮ ФАБРИКАСЫНДА

3 нче гыйнварда бу фабриканың 1 нче һәм 2 нче номерлы цехларында көнлек задание арттырып үтәлде. Беренче цех буенча 3 нче гыйнвар көнне задание 107,4 процент, 2 нче цех буенча 109,5 процент итеп үтәлде. Цехның аерым стахановчылары бу көнне нормаңы бер ярым, ике тапкыр арттырып үтәделәр.

ВАХИТОВ ИСМЕНДӘГЕ ЖИРКОМБИНАТТА

Казан жиркомбинаты үткән ел хезмәт җитештерүчәнлеген план буенча билгеләнгән 14 процент урнына 31 процент итеп үтәде. Продукциянең үзенә төшкән бәясен планга караганда шактый киметте. Шуның аркасында 1,8 миллион сум экономия алды.

Сталинчыл өченче бишьеллыкның өченче елында — 1940 нчы елда илебезнең алдынгы предприятиеләр коллективлары тагын да яхшырак эшләү өчен, хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да үстерү өчен яңа йөкләмәләр алалар. Москвадагы инструменталь заводы коллективы хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү буенча бишьеллык планны 4 елда үтәргә чакырды.

Жиркомбинатта да хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү буенча планны дүрт елда үтәү өчен мөмкинлекләр зур. Стахановчылар гаят яхшы эш үрнәкләре бирәләр. Аларның саны көн саен артып тора.

Комбинатта 1937 нче елда бер эшче уртача 23.500 сумлык продукция җитештергән булса, (1926—27 нче елгы бәяләр белән) 1939 нчы елны һәрбер эшче уртача 41 мең сумлык продукция җитештергән. 1940 нчы елда һәрбер эшче уртача 43 мең сумлык продукция җитештерәчәк.

Хәзер комбинатта хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү буенча Сталинчыл өченче бишьеллык планны дүрт елда яки аннан да кимрәк вакыт эчендә үтәү өчен тиешле чаралар күрелә. Комбинатның җитәкчеләре һәм эшчеләре 1940 нчы елда тоташ стахановча эшләүче комбинат булу бурычын куялар. Сабын һәм шәм заводларында бракны киметүне йөкләмә итеп алдылар. Моның өчен эш урыннары тагын да яхшырак итеп оештырыла. Эш процесслары үзгәртеп төзелә. Туалет цехына реконструкция үткәрелә. Бу, туалет цехында хезмәт җитештерүчәнлеген күп тапкыр үстерүне тәэмин итәчәк.

К. Халиков.

Авыл Хуҗалыгы институтының гомуми игенчелек кафедрасы фәнни работникларыннан җирле Советларга депутат итеп 4 иптәш сайланды. РӘСЕМДӘ (сулдан уңга): Молотов район Советы депутатлары—аспирант Н. Н. Чхеидзе һәм доцент А. К. Вершинин, Казан Шәһәр Советы депутаты аспирант М. М. Дәүләтшин һәм Молотов район Советы депутаты өлкән лаборант З. Н. Мамаева иптәшләр.

И. Папков фотосы (ТатТАСС фотохроникасы)

РАЙОН СОВЕТЛАРЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ СЕССИЯЛӘРЕ

ЮТАЗЫ РАЙОНЫ

ЮТАЗЫ, 4 гыйнвар. (ТатТАСС). Хезмәт ияләре депутатларының Ютазы район Советының беренче сессиясе булып үтте. Сессияне Советның иң карт депутаты— орденлы Елизавета Константиновна Рязанова ачты. Үзенең речендә иптәш Рязанова болай диде:

— Мин хезмәт ияләре депутатлары Советының беренче сессиясен ачу кебек зур бурычны үтәү бәхтенә ирештем. Районыбызның хезмәт ияләре, безне район Советының депутатлары итеп сайлау белән, безгә зур ышаныч һәм ихтирам күрсәттеләр. Без бу ышанычны акларга тиешбез. Без күңел биреп эшләргә, сөекле юлбашчыбыз бөек Сталин өйрәткәнчә эшләргә тиешбез.

Иптәш Рязанованың соңгы сүзләре депутатларның көчле кул чабулары белән каршы алынды.

Депутат иптәш Әхмәтҗановның тәкдиме буенча сессияне алып бару өчен председатель итеп депутат Миңлебаев, секретарь итеп депутат Исхакова иптәшләр сайланды. Сессия башкарма комитетның составын раслады. Башкарма Комитетның председателе итеп депутат Фатыйх Шириаздан улы Шириазданов, председатель урынбасары итеп депутат З. Ш. Әхмәтҗанов, секретарь итеп З. Ш. Тимбаков иптәшләр сайланды.

Сессия биш даими комиссия төзеде һәм райсовет башкарма комитетының бүлек мөдирләрен раслады.

ЛАЕШ РАЙОНЫ

ЛАЕШ, 4 гыйнвар. (ТатТАСС). 3 нче гыйнварда район клубында хезмәт ияләре депутатларының Лаеш район Советының беренче сессиясе булды. Сессияне иң карт депутат—65 яшьлек колхозчы Максим Павлович Ермаков ачты. Сессияне алып бару өчен председатель итеп депутат Михаил Иванович Карпов, секретарь итеп депутат—урта мәктәп укытучысы Анастасия Николаевна Глаголева сайланды.

Өч депутат составында бер тавыштан мандат комиссиясе сайланды. Депутат иптәш Романовның тәкдиме буенча сессия 11 кеше составында башкарма комитет сайлау турында карар кабул итте. Иптәш Романов башкарма комитет председателе итеп Татарстан АССР Верховный Советы депутаты һәм район советы депутат Хәбиб Җәлалетдин улы Мифтаховны сайларга тәкдим итә. Бу тәкдим бер тавыштан кабул ителә. Председатель урынбасары итеп, депутат Михаил Петрович Калин, секретарь итеп депутат Михаил Яковлевич Чернов сайланды.

Аннары, депутат иптәш Мифтаховның тәкдиме буенча сессия район Советының 8 бүлеген: җир, финанс, сәламәтлек саклау, сәүдә, юл төзелеше, халык мәгарифе, социал тәэминат һәм гомуми бүлек, шулай ук план комиссиясе һәм кадрлар секторы төзү турында карар кабул итә.

Бүлек мөдирләре һәм план комиссиясе председателе расланганнан соң, сессия мандат комиссиясенең докладын тыңлады һәм раслады.

Кичке утырышта депутат Михаил Васильевич Пятков даими эшләүче комиссияләр: бюджет, мәктәп, сәүдә, сәламәтлек саклау, коммуналь һәм хәрби-физкультура комиссияләре сайлау турында тәкдим кертә. Сессия бу тәкдимне бер тавыштан кабул итте һәм 6 даими комиссия оештырды.

Шуның белән хезмәт ияләре депутатларының Лаеш район Советының беренче сессиясе ябылды.

БИЛӘР РАЙОНЫ

Хезмәт ияләре депутатларының Биләр район Советының беренче сессиясе булды. Советның иң карт депутаты иптәш Гыйниятуллин, сессияне ачканда, барлык депутатларны социалистик Ватанның бәхте өчен бердәм һәм энергия белән эшләргә чакырды.

— Без атабыз һәм юлбашчыбыз, сөекле Сталин өйрәткәнчә эшләргә тиешбез. Сайлаучыларыбызның ышанычларын аклау өчен без бөтен көчебезне бирергә тиешбез,—диде иптәш Гыйниятуллин.

Сессия башкарма комитет төзеде, башкарма комитет бүлекләренең мөдирләрен раслады, район советының даими комиссияләрен оештырды һәм мандат комиссиясенең докладын раслады.

ПРОПАГАНДА ҺӘМ АГИТАЦИЯ РАБОТНИКЛАРЫНЫҢ ӨЛКӘ КИҢӘШМӘСЕ

4 нче гыйнварда, кич 6 сәгатьтә, Менжинский исемендәге клубта пропаганда һәм агитация работникларының өлкә киңәшмәсе башланды.

Киңәшмәдә ВКП(б) райкомнарының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдирләре, пропагандистлар, лекторлар һәм парткабинет мөдирләре катнашалар.

Киңәшмәне ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Алемасов ача.

Киңәшмәнең көн тәртибендә ике мәсьәлә тора: беренчесе— партия пропагандасын үзгәртеп коруның йомгаклары турында; икенчесе—халык арасында агитация-масса эшенең бурычлары турында.

Беренче мәсьәлә буенча ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Матвеев докладны тыңланды.

Доклад буенча фикер алышуларда Бухараев (ВКП(б) Өлкә Комитеты лекторы), Садаев (Буденный райкомы пропагандисты), Буканов (Кузнечиха райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире), Антонов (Биләр райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире) иптәшләр сөйләделәр.

Киңәшмәнең бүгенге утырышында иптәш Матвеев доклады буенча фикер алышулар дәвам итә.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

3 нче гыйнварда фронтта әйтерлек бер нәрсә дә булмады.

Болгариянең сәүдә делегациясе башлыгы Божилов әфәндене иптәш Молотовның кабул итүе

Кичә, 4 нче гыйнварда, СССР Халык Комиссарлары Советы Председателе һәм Чит Ил Эшләре Халык Комиссары иптәш **В. М. Молотов** Болгариянең сәүдә делегациясе башлыгын — Болгария финанс министре Божилов әфәндене кабул итте.

Кабул итүдә Болгариянең Москвадагы илчесе Антонов әфәнде һәм Чит Ил Эшләре Наркомының Урынбасары иптәш В. Г. Деканозов катнаштылар.

СОВЕТЛАР СОЮЗЫНДА

ЗУР ОТЫШЛАР

3 нче гыйнварга СССР Осоавиахимы Үзәк Советына лотерея буенча 7 данә җиңел „М—1“ автомашинасы, бер „ЗИС— 101“ автомашинасы, 23 мотоцикл, 16 пианино, 41 радиола, СССР буенча 18 сәяхәт һәм башка отышлар чыккан билетлар алынган.

СТАЛИНО ШӘҺӘРЕНДӘ ТРОЛЛЕЙБУС

Сталино шәһәрендә 3,5 километр озынлыгында беренче троллейбус линиясе төзү тәмам булды. Бу линия Сталин исемендәге заводтан студентлар шәһәрчегенә сузылган. Трассада бик яхшы биш троллейбус йөриячәк.

83 МИЛЛИОН 500 МЕҢ БАНКА КОНСЕРВ

Херсонның Сталин исемендәге һәм 8 нче Март исемендәге консерв заводлары үткән елны илебезнең төрле шәһәрләренә 83.500 банка яшелчә һәм фрукта консервасы җибәрделәр. Бу заводлар икесе дә планнан тыш 5 миллион банкадан артык консерв бирделәр.

ХРОНИКА

ССР Союзы Совнаркомы Төркиядә җир тетрәүдән зиан күргәннәргә ярдәмгә 10 мең доллар акча җибәрергә карар бирде.

СССР ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНДӘ

Фотоэлементлар станокларның эшләрен регулярләштерәләр

СССР Фәннәр Академиясенең телемеханика һәм автоматика институтында фотоэлементларны промышленностьта куллануның яңа системасы эшләнә. Маглүм ки, әлегә кадәр бу эш фотоэлементларның физик сыйфатларының даими булмавы аркасында кыенлыкка очрап килә иде. Хәзер академик В. С. Кулибакин җитәкчелегендә институтның өлкән фәннәр сотруднигы Б. Е. Телешевский фотоэлементларның физик сыйфатлары даими булмауга механизмнар эшенең бәйлелеген бетерә алды. Бу хәл производствоның төп процессларын, детальләрнең зурлыгын, эрегән металның дәрәҗәсен һәм аның температурасын, газларның басымын, нефть расходын автомат юл белән бик дөрес итеп регулярләштерергә мөмкинлек бирә. Яңа система детальләрне кеше ярдәменнән башка—чертежлар буенча гына хәзерләүче станоклар төзергә мөмкинлек бирәчәк.

Күп станокта эшләгәндә фотоэлементлардан файдалануның әһәмияте аеруча зур. Станокларны автомат юл белән эшләтү эшчеләрне производствоның төп процессларына өзлексез контроль ясау кирәклегеннән азат итә. Бу хәл күп станокларда эшләүчеләрнең эшен җиңеләйтәчәк һәм хезмәт җитештерүчәнлеген бик нык күтәрәчәк.

Фәннәр Академиясе лабораторияләрендә фотоэлементлар белән тәҗрибәләр соңгы вакытка кадәр уңышлы үткәрелделәр. Хәзер Совет фәненең бу яңа казанышы производствога кертеләчәк.

ХАРЬКОВТА СОЦИАЛИСТИК ИГЕНЧЕЛЕК АКАДЕМИЯСЕ

Харьковта Артем исемендәге Украина Коммунистик Авыл Хуҗалыгы Университеты базасында Артем исемендә социалистик игенчелек академиясе төзелә. Коммунистик университет укучылары арасында СССР Верховный Советы депутаты У. Н. Бондаренко, орденлы звено башлыклары Мария Пилипенко һәм Анна Канцибер, УССР Верховный Советы депутаты ике тапкыр орден алган Х. Ф. Рыльская һәм башкалар бар.

СТАЛИНСК—АЛТАЙ ТИМЕР ЮЛЫ

Сталинск—Алтай тимер юлын төзү буенча эзләнү эшләре тәмам булды һәм техник проект төзү башланды. Бу яңа юлның озынлыгы 208 километр. Ул Сталинск—Барнаул—Акмолинск— Магнитогорск юлының бер өлеше булачак.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

КОММУНИСТЛАР ПРОИЗВОДСТВОДА АВАНГАРДЛЫК КҮРСӘТӘЛӘР

Казандагы Мехкомбинат 1939 нчы елның производство планын срогыннан алда—15 нче дәкабрьгә тулысы белән үтәде.

Производство планын үтәүдә коммунистлар аеруча алдынгылык күрсәттеләр. 4 нче мех фабрикасында эшләүче стахановчы коммунистлардан Гатауллина, Калчурина, Нурмөхәметова, Мөхәмәтшина, Сиражиева, Тупишин һәм Клементьева иптәшләр еллык производство планнарын ноябрь аенда ук 180—200 процент итеп үтәделәр. Алар производствода стахановчы булу белән бергә, җәмагат эшләренә дә актив катнашалар. Алар агитатор булып эшлиләр һәм эшчеләр арасында политик-масса эшләре алып баралар. Үзләренең эш тәҗрибәләрен башкаларга күчерәләр. Мәсәлән, стахановчы Гатауллина үзенең эш тәҗрибәсен 16 эшчегә өйрәткән. Иптәш Гатауллина методы белән эшләп, бу эшчеләр дә стахановчы дигән мактаулы исемне яулап алуга ирешкәннәр.

Даһи юлбашчыбыз иптәш Сталинга 60 яшь тулу көненә карата партоешманың инициативасы белән оештырылган стахановчылык вахтасы эштә аеруча зур нәтиҗәләр бирде. Бу көнне фабрика эшләп чыгаруның көнлек планын 160 процент итеп үтәде.

Партоешма секретаре иптәш Нагаткин, стахановчылык хәрәкәтенә системалы җитәкчелек итә. Стахановчыларның киңәшмәләрен үткәрә. Алар белән аерым беседалар ясый. Стахановчылык хәрәкәте фабрика коллективы арасында киң җәелдерелде. Фабрикада эш нормасын үтәмәүче бер генә кеше дә юк.

Бу фабрика еллык производство планын яхшы сыйфат белән 20 нче ноябрьгә тулысынча үтәп яңа елга кадәр тагы 1 миллион 200 мең сумлык продукция эшләп чыгарырга йөкләмә алган иде. 25 нче декабрьгә ул йөкләмә дә тулысынча үтәлде.

Партоешма коммунистларны идея-политик яктан тәрбияләү һәм аларны эш процессында үстерү белән системалы рәвештә шөгыльләнә. Шуның нәтиҗәсендә соңгы айларда гына да коммунистлардан 12 кеше җитәкче постларга күтәрелде. Алар арасында гади эшчедән смена мастеры булып күтәрелгән Грачов һәм смена мастерлыгыннан цех начальнигы булып күтәрелгән Люткина иптәшләр бар. Иптәш Космасов моннан берничә ел элек бу фабрикага бүрек тегүче булып эшкә кергән иде. Партоешманың системалы рәвештә ярдәм итүе нәтиҗәсендә ул алдынгы эшче булып әверелде. Коллектив алдында зур авторитет казанды һәм производство киңәшмәләре буенча директор урынбасары булып күтәрелде. Бу эшне дә намус белән башкарды һәм озак та үтми тагы да югары постка—фабриканың техник директоры постына күтәрелде. Иптәш Космасов производствога рационализация чаралары кертүгә зур игтибар бирә. Ул „Искимус“ кисүне рационаллаштырды. Шуның нәтиҗәсендә фабрика елына 12.863 сум экономия ясады. Бу чаралар хезмәтнең эшләп чыгарышын нык күтәрде һәм продукциянең сыйфатын яхшыртты. Иптәш Космасов актив коммунистларның берсе. Ул үзенә тапшырылган җәмагат эшләрен дә зур активлык белән үти. Үзенең теоретик белемен һәм квалификациясен күтәрү өстендә эшли, производстводан аерылмыйча плановиклар курсын тәмамлады һәм хәзерге вакытта промакадемиягә керергә хәзерләнә.

Хаҗиев. Сибатов.

КОЛХОЗ АКТИВЫН ТӘРБИЯЛӘҮГӘ ИГТИБАР ҖИТӘРЛЕК ТҮГЕЛ

Питрәч районында Вахитов исемендәге колхоз иң зур колхозларның берсе булып санала. Бу колхозда соңгы елларда күп кенә яңа кадрлар үсте. Авыл советы һәм колхоз празлениесе тирәсенә 50 дән артык активист тупланган. Хәзер колхоз бригадирлары булып 13, звено башлыклары булып 34 һәм авыл советы членнары булып 28 кеше эшли. Бу кадрларның күпчелеге күптән түгел генә рядовой колхозчы булып эшләгән кешеләр. Мәсәлән, иптәш Сәйфеттинев башта рядовой колхозчы иде, аннан соң бригадир булып эшләүгә күтәрелде. 1938 нче елны май аенда аны колхоз председателе итеп сайладылар. Председатель урынбасары итеп күтәрелгән иптәш Сабиров та рядовой колхозчы иде. Иптәш Г. Хәмидуллин терлекчелек фермасына мөдир итеп күтәрелде.

Җитәкче эшләргә яңа кадрларны күтәрү генә җитми, бәлки аларны тәрбияләргә, аларга практик булышлык күрсәтергә кирәк. Колхозның партоешмасына бу өлкәдә аеруча зур җаваплылык йөкләнә. Ләкин партиянең башлангыч оешмасы (секретаре иптәш Җиһаншина) бу мәсьәләгә җитәрлек әһәмият бирми әле.

Яңа күтәрелгән кадрларның эшләре турында партия җыелышларында тикшерелгәне юк. Партия оешмасы һәм авыл советы тарафыннан яңа кадрларга җәмагат эшләре бирү һәм аның үтәлешен тикшерү мәсьәләсе дә бик начар тора. Яңа күтәрелгән кадрларның эшләренә булышлык җитәрлек түгел. Сельпо председателе иптәш Сафиуллин болай ди:

— Сельпога председатель итеп күтәргәндә, булышырбыз диделәр, күп вәгъдәләр бирделәр, ә эшли башлагач килеп тә карамыйлар.

Актив киңәшмәләре үткәрелми. Колхоз кадрлары өчен фәнни-теоретик лекцияләр бер тапкыр да үткәрелгәне юк. ВКП(б) тарихын үзлекләреннән өйрәнүчеләр белән кызыксынган кеше дә юк. Партия тарихын түгәрәктә өйрәнергә теләүчеләр өчен түгәрәк оештырылмаган.

Кадрларны тәрбияләү эшенә шундый җавапсызлык булганлыктан, кайберәүләрнең эчүчелеккә бирелү фактлары да бар. Колхоз бригадирларыннан Сафин, Хәйруллин, Сабиров, Газимовлар эчүчелек белән шөгыльләнәләр. Ә партоешма секретаре бу фактлардан үзенә кирәкле нәтиҗәне ясаганы юк әле.

Партиянең район комитеты җитәкчеләренә колхоз активын большевизм рухында тәрбияләү эшен ныклы юлга кую чараларын күрергә бик вакыт инде.

Х. Гарипов.

Авыл мәктәпләре профработниклары курсында укучылар (Казан) Укытучылар йортында лектор иптәш Конгуровның халыкара хәлләр турындагы лекциясен тыңлыйлар. И. Галиев фотосы.

ПАРТИЯ ПРОПАГАНДАСЫ ҮЗ АГЫМЫНА КУЕЛГАН

Ленин районындагы коммунистлардан 825 кеше, комсомолецлардан 700 кеше һәм партиясезләрдән 418 кеше Ленин—Сталин партиясе тарихын үзлегеннән өйрәнә. Алар өчен 40 ка якын лекция, 9 тапкыр беседа һәм 15 тапкыр киңәшмә үткәрелде.

Партия тарихын өйрәнүдә яхшы күрсәткечләр бирүче иптәшләр районда аз түгел. „Совет Киноплёнкасы“ газетасы редакторы, ВКП(б) членнары Глухов, Николин иптәшләр 7 нче бүлекне, Казкинохимстройдан ВКП(б) кандидаты иптәш Зубов 6 нчы бүлекне өйрәнә. ВКП(б) члены укытучы иптәш Толмачев, партиясез интеллигентлардан 18 кеше „Кыскача курс“ның ун ике бүлеген дә бер кат конспект язып өйрәнеп чыктылар. Хәзер алар ВКП(б) тарихын беренче чыганаклар буенча янадан тирәнтен өйрәнәләр.

Фото-желатин заводы янындагы партоешма (секретаре иптәш Миңнуллин) тарафыннан үткәрелгән теоретик конференциягә партиясез интеллигентлардан 35 кеше катнашты, 16 кеше чыгып сөйләде. 14 нче номерлы трест янындагы партоешма (секретаре иптәш Горбунов) районда беренче буларак, „Кыскача курс“ның 4 нче бүлеге буенча теоретик конференция үткәрде. Конференциядә 5 кеше чыгып сөйләде һәм 20 дән артык сораулар бирелде.

Шулай да районда партия пропагандасының куелышы һич тә канәгатьләнерлек түгел әле.

Җитәкче работниклардан кайбер иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнүдә артта баралар. Мәсәлән, райком секретарьлары Алимов һәм Филиппов иптәшләр үзләре дә 3 нче бүлекне генә өйрәнәләр. 14 нче номерлы трест янындагы партбюро секретаренең урынбасары иптәш Шакуров 1 нче бүлекне дә өйрәнеп бетермәгән. 14 нче номерлы трест управляющие иптәш Баринов 3 нче бүлекне генә өйрәнә.

Партия тарихын начар өйрәнүчеләрдән тагын күп кенә җитәкче работникларны күрсәтергә мөмкин.

ВКП(б) тарихын өйрәнү эшенә бөтенләй керешмәгән коммунистлар да бар. Кино техникумы янындагы партоешмадан Абдрахманов һәм Толкушкин иптәшләр шулар исәбенә керәләр. Иптәш Абдрахманов „Мин „Кыскача курс“ны өйрәнәм“ дип белдергән иде. Ләкин сөйләшеп караганнан соң, аның теоретик яктан бөтенләй артта калганлыгы билгеле булды.

ВКП(б) райкомы янындагы партоешмада пропаганданың куелышы турындагы мәсьәлә бары бер тапкыр тикшерелгән. Тәҗрибә уртаклашу буенча бер тапкыр да киңәшмә булмаган. Район Советы һәм ДОК янындагы партоешмаларда партия пропагандасы эшенә җитәкчелек итмиләр.

Бу фактлар барсы да кайбер аерым башлангыч партоешмаларның, ВКП(б) район комитетының һәм аның секретарьларының пропаганда мәсьәләләре белән ВКП(б) Үзәк Комитеты таләп иткәнчә шөгыльләнмәүләрен ачык күрсәтәләр.

А. Овчинников.

МАССОВЫЙ-ОБОРОНА ЭШЕ ЯХШЫРА

ВКП(б) ның тарихи XVIII нче съездыннан соң Арча районында массовый - оборона эшләре шактый яхшырды. ВКП(б) райкомы һәм партиянең башлангыч оешмалары колхозлар, предприятиеләр, учреждениеләр янындагы массовый - оборона оешмаларының эшләренә конкрет ярдәм итәләр. ВКП(б) райкомы янында хәрби бүлек оештырылганнан соң бу эш тагын да җанланды.

Хәзер районда 71 урында Осоавиахимның башлангыч оешмалары оештырылды. Аларның җитәкчеләре итеп коммунистлар, комсомолецлар һәм партиясез активистлар сайланды.

Винита авылында Осоавиахимның башлангыч оешмасына ВКП(б) членлыгына кандидат иптәш Иванов җитәкчелек итә. Бу оешмада 30 кеше член булып тора. Осоавиахим членнарыннан 11 кеше „Ворошиловча атучы“ значогына, 15 кеше ПВХО значогына нормалар тапшырдылар. Партоешма Осоавиахим оешмасына булышлык итә. Партҗыелышларда Осоавиахим җитәкчесенең информацияләре тыңлана.

Наласа авылы Осоавиахим оешмасы да яхшы гына эшли башлады. Бу оешманың членнарыннан 70 кеше ГСО значогына, 45 кеше ПВХО значогына нормалар тапшырдылар. Чиканас, Сөҗе һәм Казанбаш авылларындагы башлангыч оешмалар да соңгы вакытларда яхшы гына эшли башладылар. Аларда членнар саны арта бара, системалы рәвештә хәрби занятиеләр үткәрелә.

Ләкин кайбер урыннарда партия, комсомол оешмалары оборона эшләренә тиешле әһәмият бирмиләр әле. Мәсәлән, Урта Сәрдә авылындагы башлангыч партоешмада оборона эше мәсьәләләре бер тапкыр да тикшерелмәгән. Осоавиахим оешмасының председателе, ВКП(б) членлыгына кандидат иптәш Һадиев үз эшенә җавапсыз карый. Ул, Осоавиахим оешмасының эшен яхшырту, оешмага яңа членнар тарту, оборона значокларына нормалар тапшыру кебек эшләргә бөтенләй җитәкчелек итми. „Комбайн“ колхозында шушы көнгә кадәр Осоавиахимның башлангыч оешмасы оештырылмаган. Партиянең башлангыч оешмасы секретаре иптәш Әхмәтҗанов бу эш белән кызыксынмый да.

Партия һәм комсомол оешмаларының җитәкчеләре, массовый-оборона оешмаларының эшләрен ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарлары таләп иткәнчә оештыру өчен көрәшергә тиешләр.

Шири Җәлал.

Партия поручениеләрен үтәүдә җаваплылыкны күтәрергә

„Красный Восток“ совхозындагы (Алексеевский районы) башлангыч партоешмада 25 коммунист исәпләнә. Оешманың көче зур. Ләкин, партоешма бу көчтән тиешенчә файдаланмый. Коммунистлардан эш таләп итү җитәрлек түгел, аларга бирелгән поручениеләрнең үтәлешен тикшерүгә дә аз игтибар ителә. Үткән партҗыелышларның протоколларында бу ачык күренә. 1939 нчы ел эчендә партҗыелышлар 22 тапкыр, партбюро утырышлары 8 тапкыр булып үткән. Бу җыелышларда һәм утырышларда барлыгы 74 мәсьәлә каралган. Ләкин, поручениеләрнең үтәлеше турында коммунистларның информацияләре сирәк тыңланган. Аерым коммунистлар арасында үзләренә бирелгән поручениеләрне үтәүгә җавапсызлык туган.

Оешмадагы коммунистларның һәрберсе диярлек агитатор итеп билгеләнгәннәр. Ләкин, бу мактаулы эшне кайбер коммунистлар үтәмиләр. Мәсәлән, Королев, Галактионов һ. б. иптәшләр соңгы ике айда берәр занятие дә үткәрмәгәннәр. Шулай да бу фактлар партоешманы кызыксындырмыйлар.

Партия кандидаты иптәш Талалаевка тракторчы хатын-кызлар түгәрәге оештыру эше тапшырылган иде. Түгәрәкне оештыру өчен бөтен мөмкинлекләр булып та, ул бу эшне үтәмәде. Политбүлек начальнигы ярдәмчесе иптәш Булкин да бу әһәмиятле эшкә игтибар итмәде.

Партоешма һәрбер коммунистка поручениеләр бирергә, һәм ул поручениеләрнең төгәл үтәлүенә ирешергә тиеш.

Х. Җиһаншин.

МТС партоешмаларының эше турында

Актаныш МТС ы республикабызда иң алдынгы МТС ларның берсе. Бу МТС 1939 нчы елны дәүләт планын 121 процент үтәде.

МТС ның алдынгы бригадаларыннан стахановчы иптәш Әһли Әглямов бригадасы у—2 тракторлары белән, йомшак җир сөрүгә күчерелгәндә, һәрбер тракторга уртача 1.390 гектар, Махъян иптәш Хабиев бригадасы 1.155 гектар эшләде. Тракторчы стахановчылардан 62 кеше 1940 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашу өчен кандидат булып тора. Хәзер МТС коллективы тракторларны һәм башка авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлау планын яхшы сыйфатлы итеп, кыска срокта үтәү өчен нык көрәш алып бара. Тракторчылар һәм башка эшчеләр арасында социалистик ярыш киң җәелдерелгән.

МТС коллективының бу казанышлары турыдан-туры МТС янындагы башлангыч партоешма тарафыннан алып барыла торган политик-тәрбия эшләренә бәйләнгән. Политик эшне хуҗалык эшләре белән дөрес итеп бәйләп алып бару—бу оешманың эшендә төп принцип булып тора.

Актаныш МТС ы янындагы партоешмада коммунистларның җыелышлары алдан яхшы хәзерлек белән, айга ике тапкыр үткәреләләр. Ул җыелышларда үзәк мәсьәләләрнең берсе булып: үтәлешне тикшерү, коммунистларны тәрбияләү, производство эшенә партоешманың контроль оештыруы турындагы мәсьәләләр торалар. Производство эшен контроль астына алу партия җыелышларында докладлар тыңлау һәм карарлар чыгару белән генә чикләнелми, бәлки аерым тармаклардагы эшләрнең торышы коммунистлар һәм партиясез активистлар катнашы белән тикшерелә, өйрәнелә, ә кай вакытларда аерым мәсьәләләр буенча партия җыелышларына кадәр киңәшмәләр үткәрелә. Карарларны үтәү эшенә партияле һәм партиясез активистлар тартыла. Билгеле вакыт узганнан соң, карарларның үтәлешләре тикшерелә һәм ул турыда партия җыелышларында яки производство киңәшмәләрендә информацияләр тыңлана. Шулай итеп эшләү нәтиҗәсендә, партоешма үз карарларының үтәлешен тәэмин итә.

Бу партоешма янында 18 кешене эченә алган агитколлектив бар. Партоешма секретаре иптәш Газизов айга ике тапкыр агитаторларның киңәшмәләрен җыя һәм алар белән консультация үткәрә. Биредә масса-агитация эшләре көндәлек производство мәсьәләләре белән нык лы рәвештә бәйләп алып барыла. Алдынгы стахановчыларның эш тәҗрибәләре, яки аерым стахановчыларның үз планнарын ничек итеп үтәүләре агитаторларның көндәлек эшләрендә тулы яктыртыла.

Актаныш МТС ы коммунистлары „ВКП (б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнү буенча да яхшы гына эшләп киләләр. Садриев, Газизов иптәшләр бу эштә аеруча яхшы үрнәк күрсәтәләр.

Партия-политик һәм масса-аңлату эшләренең яхшы куелуы нәтиҗәсендә, оешма алдынгы кешеләр хисабына үсә. Мәсәлән, партиянең XVIII нче съездыннан соң үткән вакыт эчендә генә дә бу оешмада партия сафларына 14 кеше кабул ителде. Алар арасында МТС ның алдынгы стахановчыларыннан Вәлиев, Кадимова, Талипов, Төхфәтуллин, Шәмсиев иптәшләр бар.

Партия оешмасының җитәкчелегендә тракторчылар үзләренең техник белемнәрен күтәрү буенча стахановчылар мәктәбендә укыйлар. Анда алар авыл хуҗалыгы алдынгыларының эш тәҗрибәләрен өйрәнәләр һәм үз МТС ларындагы алдынгы бригадирларның лекцияләрен тыңлыйлар. Хезмәтне дөрес оештыру нәтиҗәсендә, Актаныш МТС ы коллективы эшләргә дә һәм үзләренең политик һәм техник белемнәрен күтәрүгә дә вакыт таба ала.

Партиянең МТС лар янындагы барлык башлангыч оешмалары да партия-политик эшне хуҗалык эшләре белән дөрес бәйләп алып баралар дип әйтеп булмый әле. Кайбер партоешмалар хәзер дә җитәкчелекнең иске методы белән эшләүдә дәвам итәләр. Мисаль өчен Калинин МТС ы янындагы башлангыч партоешманы алырга мөмкин. Бу оешма (секретаре иптәш Шакиров) партия-политик эш белән бик начар шөгыльләнә. Бу оешмада партия җыелышлары хәзерлексез үткәреләләр. Коммунистларга конкрет поручениеләр бирү һәм аларның үтәлешләрен тикшерү практикага кертелмәгән. Тракторчылар һәм МТС тагы башка эшчеләр арасында масса-политик эшләр тиешле югарылыкта түгел. Партоешманың производствога контроле йомшак.

МТС та хезмәтне оештыру эше һәм хезмәт дисциплинасы һич тә канәгатьләнерлек түгел. Ремонтта эшләүчеләр үзара социалистик ярыш белән чолганып алынмаганнар. МТС ларда политик эш белән хуҗалык эшләре дөрес итеп бәйләп алып барылмый.

Шулар нәтиҗәсендә, бу оешмада партия сафлары әкерен үсә: быел партия сафларына бары 3 кеше кабул ителгән. МТС та хуҗалык эшләре дә бик начар тора. МТС 1939 нчы елны тракторлар белән эшләү планын бары тик 70 процент үтәгән. Шулай ук бу көнгә кадәр бер тoракторга да ремонт ясалмаган.

Политик эшне онытып, хуҗалык эшенә генә бирелү большевизмга никадәр чит булса, хуҗалык эшеннән читләшү дә аның өчен шул кадәр чит. Бу турыда партия Үзәк Комитетының февраль-март Пленумында иптәш Сталин болай диде:

„Безнең партияле иптәшләрнең хуҗалык уңышлары белән мавыгып, политикадан читкә китүләре, бездән зур корбаннар алган бер читкә китү иде. Әгәр дә хәзер безнең кайбер иптәшләр, партия-политик эшне көчәйтергә керешеп, хуҗалыктан читкә китәргә уйласалар, ул вакытта бу бездән корбаннарны шуннан да ким алмый торган икенче читкә китү булыр. Бер читтән икенчесенә ташланырга ярамый“.

Иптәш Сталинның бу кисәтүен партиянең барлык оешмалары да тулы үзләштерергә һәм практик эштә шуннан чыгып эш итәргә тиешләр.

Хәзер МТС партоешмалары алдында төп бурыч, ВКП(б) Өлкә Комитетының 10 нчы декабрь карарын үтәүгә МТС коллективын туплау һәм язгы чәчүне большевистик хәзерлек белән каршылаудан гыйбарәт. Бу бурычны үтәү—МТС ларда партия-политик эшне тагын да яхшырту, партия оешмаларының масса белән элемтәләрен тагын да ныгыту һәм партия оешмалары алдында торган политик-хуҗалык бурычларын уңышлы үтәү билгесе астында алып барылырга тиеш.

Н. Вәлиев.

ПРОПАГАНДА ЭШЕН КӨЧӘЙТИК

Кукмара районында партия тарихын үзлегеннән өйрәнү эше сизелерлек яхшырды.

Бу эштә коммунистлар һәм комсомолецлар аеруча яхшы эшлиләр. Әминев һәм Герасимов иптәшләр „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н конспект төзеп өйрәнделәр, хәзер алар марксизм - ленинизм классикларының аерым әсәрләрен өйрәнергә керештеләр. Укытучылардан Хафизов, Гобәйдуллин, „Кызыл Тукучы“ фабрикасының күп тиражлы газетасы редакторы Гаянов һәм спец часть начальнигы Котельников иптәшләр „Кыскача курс“ның VI—VIII нче бүлекләрен өйрәнәләр. Партия тарихын үзлегеннән өйрәнүчеләр лекцияләргә, консультацияләргә һәм докладларга системалы рәвештә йөриләр һәм аларда актив катнашалар.

Теоретик белемнәрен күтәргән иптәшләр практик эшкә дә яхшы җитәкчелек итәләр. Гобәйдуллин, Әминев иптәшләр мәктәп директорлары булып эшлиләр. Алар җитәкчелек итә торган мәктәпләрдә уку елының беренче чиреге яхшы күрсәткечләр белән тәмамланды. Бу мәктәпләрдә пионер һәм комсомол оешмалары үсте һәм җәмагат эшләренә катнашулары яхшырды.

Иптәш Гаянов үзенең теоретик белем дәрәҗәсен күтәрүе нәтиҗәсендә, практик эшендә зур гына уңышларга ирешге, газетаның сыйфаты шактый яхшырды. Партия тарихын өйрәнүчеләр өчен консультация материаллары һәм „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнүчеләрнең тәҗрибәләре газетада системалы яктыртыла һәм газетаны укучылар саны да көннән-көн арта бара. Хәзер иптәш Гаянов ВЛКСМ ның фабрика комитеты секретаре итеп күтәрелде.

Шушы көннәрдә генә әле парткабинетта һәм Оштырма-Юмья авылында тарихи материализм турында лекция укылды. Лекцияне 300 дән артык кеше тыңлады һәм күп кенә сораулар бирелде.

Шуның белән бергә, барлык мөмкинлекләре булуга да карамастан, „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнүгә керешмәгән иптәшләр дә бар әле. ВЛКСМ райкомы бюросы членнары Насыйбуллин, Яркиев иптәшләр кыскача курсның беренче бүлеген генә „өйрәнәләр“. „Селхозснаб“, „Заготлень“, „Заготскот“ның Кукмара район бүлеге мөдирләре Зарипов, Гумеров, Мөбарәкшин иптәшләр „вакыт юк“ дип „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнмиләр. Алар үзләренең теоретик белемнәрен күтәрмиләр һәм шуның нәтиҗәсендә үзләренең практик эшләрен дә йомшак үтиләр.

Березняк, Кукмара поселкы советы янында, Зур Кукмара һәм Өлге авылларында ВЛКСМ ның башлангыч оешмалары секретарьлары (Степанов, Сәгыйтова, Сәлмәнев һәм Саттаров иптәшләр) үзләре дә „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н өйрәнә башламаганнар әле. Бу оешмаларда комсомолецлар һәм союздан тыш яшьләр арасында пропаганда эше үз агымына куелган.

Коммунистлар һәм комсомолецлар үзләренең теоретик белемнәрен күтәрү өстендә, марксизм-ленинизм теориясен үзләштерү өстендә тагын да яхшырак эшләргә тиешләр.

Ә. Солтанов.

Ашханәләр эшенә ныклы контроль булдырырга

(„Кызыл Татарстан“ның рейд материалларыннан)

ҮЗЕ ЕРАК, ҮЗЕ КЕЧКЕНӘ...

2 нче номерлы тегү фабрикасы ашханәсенең адресы болай: Ул, фабрикадан ике квартал ераклыкта, „Казанское подворье“ гостиницасының ишек алдындагы кечкенә бер йортта. Әйе, кечкенә. Анда бер юлы бары 40—50 кеше утырып ашарлык урын бар. Ә фабрикада 2 меңгә якын кеше эшли.

Фабрикада ашханә мәсьәләсе берничә еллардан бирле шулай кискен хәлдә тора. Ашханәне зурайту яки яңаны төзү турында тиешле чара күрелгәне юк.

Ашханәгә керү белән шундый хәлне күрсәң: тәртип җитәрлек түгел, талоннар сата торган касса янында чират. Официанткалар бик акрын кыймылдыйлар. Ә эшчеләргә ашау тәнәфесе өчен бирелгән ярты сәгат вакыт эчендә ашханәгә барырга, чират торып аш алырга, өстәл янында урын бушаганны көтеп торырга, ашарга һәм эш башланганчы цехка кайтып җитәргә кирәк. Бу „процесс“ны үтү өчен үтә житезлек, тимер нерва, зур сабырлык кирәк!

Ашханәнең санитария-гигиена ягы да мактарлык түгел. Кухня пычрак. Кострульләр һәм савыт-сабалар чиста итеп юылмыйлар. Алар бик күп вакытлардан бирле лудить ителмәгәннәр. Бу турыда эшчеләр контроленең берничә акты да бар.

Без: „Сездә жалоба кнәгәсе бармы?“ дип сорадык. Ашханә мөдире ярдәмчесе иптәш Суханов безгә бер кнәгә китереп бирде һәм зур канәгатләнү белән, аның соңгы битен ачып күрсәтте. Анда яхшы эшләве өчен ашханә коллективына рәхмәт белдерелгән. Бу бик яхшы, әлбәттә. Ләкин шул ук вакытта бу кнәгәдә 30 дан артык жалоба бар. Аларның һәр берсендә ашханәдәге тәртипсезлек, официанткаларның эшчеләр белән начар мөгамәлә итүләре, ашның сыйфаты начар булу һәм башкалар турында язылган. Бу жалобаларның күбесенә чара күрелү турында җавап бирелмәгән.

Ашханәдә көндезге 12 сәгаттән алып 4 кә кадәр һәр кемгә сату өчен коммерческий бәяле ашлар хәзерләнә. Бу чара соңгы айларда ашханәнең эшен бер кадәр яхшыртуга ярдәм итте. Ашханә файдага эшли башлады. План артыгы белән үтәлә. Эшнең болай яхшыруга таба борылыш ясавы ашханәдә эшчеләргә хезмәт күрсәтүне тагын да яхшырту, ашның бәясен киметү өчен хезмәт итәргә тиеш иде. Ләкин ашханә җитәкчеләре эшнең бу ягын бөтенләй онытканнар. Алар коммерческий бәяле ашлар хәзерләү эше белән кирәгеннән артык мавыгып китеп эшчеләр турында аз кайгырта башлаганнар. Соңгы вакытларда эшчеләр өчен хәзерләнгән ашны еш кына чит кешеләргә сату фактлары да бар.

Ашханәдә эшчеләргә хезмәт күрсәтү һәм ашның сыйфатын яхшырту өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Кышка җитәрлек яшелчә хәзерләнгән. Башка төрле продукт белән тулы тәэмин ителгән. Бары тик алардан яхшы файдаланасы гына бар.

Ф. Сагдеева.

РЕСТОРАННАР ТРЕСТЫНЫҢ БЕР АШХАНӘСЕ ТУРЫНДА

Җәмагат туклануын үрнәк булырлык итеп оештыру өчен бездә чикләнмәгән мөмкинлекләр бар. Ләкин рестораннар тресты җитәкчеләре җәмагат туклануының сыйфатын яхшырту өчен, продуктларга мул, культуралы ашханәләр һәм буфетлар өчен җитәрлек көрәшмиләр. Трестның 20 нче номерлы ашханәсен (Энергокомбинат) алып карыйк. Бу ашханә һәм аның буфетлары гадәттән тыш начар эшлиләр. Җавапсызлык, тәртипсезлек шул чаклы урын алган, буфетта чәй дә булмый.

Комбинатның казаннар цехы буфетында бары арыш икмәге генә була. Кайбер көннәрне икенче һәм өченче сменаларда эшләүчеләр өчен арыш икмәге дә булмый. Көндезге сменаларда аш вактында тарелкалар, кашыклар җитешмәгәнлектән, эшчеләр шактый вакыт чират торалар. Ашханә мөдире Борисова һәм цех начальнигы Кулачков иптәшләр бу тәртипсезлекләрне бетерү өчен чара күрмиләр. Буфетның начар эшләве турында байтак сигналлар бар. Ләкин бу сигналларга ни өчендер колак салмыйлар. Казаннар цехында эшләүче Кашафеттинов, Закирова, Максимова һәм башка иптәшләр тарафыннан бирелгән сигналлар байтак вакытлардан бирле нәтиҗәсез яталар. Моңа комбинатның завком председателе иптәш Сафиуллин да игтибар бирми. Мәсәлән, комбинатның күп тиражлы газетасында „Иптәш Закировага җавап“ дигән материал урнаштырыла. Бу материал Казаннар цехы буфетчысы Сучикованың җинаятле практикасы турында була. Ләкин ашханә мөдире иптәш Борисова Сучикованы яклап калдыра һәм аны икенче буфетка урнаштыра.

Кухнәдә зур кимчелекләр бар. Кастрюльләр чиста түгел, аш савытлары гадәттә кайнар су белән юылмыйлар. Күмер ягу өчен плита яраксыз, плитадан һәр вакыт төтен чыга, кухнәдә винтеләция юк. Кайнар су килә торган трубалар ватык килеш торалар. Тишек трубалардан идәнгә су ага. Бу җитешсезлекләр турында эшчеләр контроле тарафыннан актлар төзелгән. Ләкин плитага һаман ремонт ясалмаган әле.

Ашханәдә дә чисталык начар, монда да трубалардан идәнгә су ага. Ашханәнең түбән каттагы залында ватык өстәл, җимерек урындыклардан башка бер нәрсә дә юк. Шунда ук зур хәрефләр белән: „Эшчеләрнең ял бүлмәсе“ дип язылган вывеска бар. Ләкин бүлмәсе булса да, аннан һич кем дә файдаланырлык түгел, ташландык хәлдә тора.

Рейд бригаласы члениарыннан:
З. Садыйкова, Һ. Рәхмәтуллина.

КОНТРОЛЬСЕЗЛЕК НӘТИҖӘЛӘРЕ

Киез итек-фетр фабрикасының ашханә җитәкчеләре эшчеләрне югары сыйфатлы аш белән тәэмин итүгә аз игтибар итәләр. Эшчеләр шактый вакыт аш көтеп чират торалар. Шунлыктан, кайберәүләр хәтта ашамыйча да калалар. Ашханәдә чисталык начар. Бер смена эшчеләре ашап чыккач, икенче сменадан ашарга керүчеләр җыештырылмаган, чистартылмаган өстәлләрдә ашарга мәҗбүр булалар.

Аш бирүчеләр арасында хезмәтне оештыру эше бик начар тора. Аш бирүчеләргә өстәлләр билгеләнмәгән.

Продуктларның сыйфаты яхшы, ә ашлар түбән сыйфатлы итеп хәзерләнә. Повар Андреев эш вактында эчүчелек белән шөгыльләнә. Хезмәт дисциплинасын бозуы өчен ул 2—3 тапкыр эшеннән чыгарылган. Ләкин ашханә мөдире иптәш Петров „кеше юк“ дигән сылтау астында, аны яңадан эшкә алган. Эшкә кире алу ярый, ләкин аны шул ук вакытта тәртипкә дә чакырырга кирәк иде, ә Андреев үзенең дисциплинасызлыгын һаман да дәвам иттерә. Повар гаебе буенча 15 нче декабрьдә аш кирәгеннән артык тозлы, ә 16 нчы декабрьдә бөтенләй тозсыз пешерелгән.

Бу ашханәдә һәр көнне 2.000—2.300 кеше ашый. Ә савыт-сабалар җитәрлек түгел. Ашханәдә бары 250 аш тарелкасы бар.

Төнге сменадагы эшчеләрне тукландыру бигрәк тә начар тора. Төнге сменада күп вакыт буфет та ачылмый. Аш бирүчеләр булмый. Кай вакытларда көндез калган ашны суык килеш бирү фактлары да бар.

Бу хәлләр җәмагат туклануына контроль юклыктан килеп чыккан. Фабком председателе иптәш Мартынов: „Минем бу эш белән шөгыльләнергә вактым булмады“ дип тынычлана.

Фабрика җитәкчеләре ашханәдә бик сирәк булалар, булган чакта да андагы тәртипсезлекләрне күрмиләр.

Рейд бригадасы членнары:
Халиков, А. Сетнов, Якупов.

М. Горький исмендәге Авыл Хуҗалыгы институтын тәмамлаучылардан (сулдан): В. Ларионов һәм П. Буланаев иптәшләр үсемлекләр лабораториясендә соңгы экзаменнарга хәзерләнәләр.
Б. Мясников фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

КЫЙММӘТЛЕ ТАКДИМНӘР

Производствоның алдынгы кешеләре—стахановчылар һәм инженер-техник работниклар уйлап табу өлкәсендә дә үрнәк күрсәтәләр, кыйммәтле такдимнәр бирәләр һәм шуның белән алар хезмәт житештерүчәнлеген күтәрүгә зур этәргеч ясыйлар.

14 нче номерлы Госсоюзстройтрестның стахановчы—рационализаторлары 1939 нчы елны байтак кыйммәтле такдимнәр керттеләр. Бу такдимнәр дәүләткә 1939 нчы елны ярты миллионга якын экономия бирделәр.

Агач әйберләре җитештерүче комбинатның җыю цехы мастеры иптәш Миняев төзелеш детальләрен чистарту буенча бик яхшы такдим кертте. Аның бу такдиме тормышка үткәрелде инде.

Паровоз депосының теплотехнигы иптәш Мерлин уйлап табучылык мәсьәләсе белән системалы рәвештә шөгыльләнә. 1939 нчы елда аның 4 такдиме тулысынча тормышка үткәрелде. Бу такдимнәрдән дәүләткә 25 мең сум экономия килә.

Инженер-механик иптәш Гордеев тимер-бетон колонналарны күтәрүнең катлаулы бурычын хәл итте. Ул колонналарны күтәрү өчен азрак көчле янәшә ике краннан файдалану эшен уйлап чыгарды. Моның нәтиҗәсендә югары бәяле көчле краннар сатып алырга туры килмәде һәм бу такдим колонналарны күтәрү һәм аларны кую эшен тулысынча механикалаштырырга мөмкинлек бирде. Бу чараларны тормышка үткәрүдән 60 мең сум экономия килә.

Инженер Беговатов, өлкән мастер Денисов иптәшләрнең дә такдимнәре зур әһәмияткә ия булып торалар.

В. Прокофьев.

ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ ҺӘМ СССР СОВНАРКОМЫ КАРАРЫН БОЗУГА ЮЛ КУЕЛМАСЫН

„Машина-трактор станцияләрендә тракторчыларның эш нормалары һәм хезмәтләренә түләү турында“ СССР Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының 1939 нчы ел, 8 нче март карары тракторлар паркыннан тулысынча һәм дөрес файдалануны оештыруда гаять көчле этәргеч булды. Ул, МТС ларда тракторчыларга нормалар һәм түләү куллану практикасында яшәп килгән аңлашылмауларны, буталчыклыкларны бетерү өчен конкрет күрсәтмә булып тора.

Бу карар нигезендә һәрбер эш төренә аерым нормалар билгеләнде. Нормадан тыш үтәлгән барлык эшләргә прогрессив тәртиптә хезмәт көне түләү системасы кертелү тракторчылар арасында хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү өчен көрәшне тагын да киңрәк җәелдерүгә ярдәм итте; яхшы сыйфатлы итеп үтәлгән эш өчен трактор бригадасы бригадирларына һәм аларның ярдәмчеләренә премия бирү тәртибен кертү югары сыйфат күрсәткечләре өчен көрәшне көчәйтте.

СССР Халык Комиссарлары Советы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карарын тормышка ашыру буенча тиешле көрәшне оештырган урыннарда машиналардан файдалануда стахановча эш үрнәкләрен бирүче алдынгылар сафы үсте.

Шулай да бу карар барлык МТС ларда да тулысынча үтәлә дип булмый әле. Һәрбер трактор бригадасында учетчы-заправщик хезмәтен бер кеше башкарырга тиеш булса да, Саба, Дөбъяз һәм Т. Тамак МТС лары бригадаларында 1939 нчы елны аерым учетчы һәм аерым заправщик штаты кертү фактлары булды. Саба МТС ы директоры иптәш Әхмәтҗанов „Трактор бригадалары өчен эчке тәртип кагыйдәләре“нә бу штатларны кертү турында махсус пункт керткән.

Учетчы заправщикка һәрбер эшләгән көнгә ике хезмәт көне түләнергә тиеш. Тәтеш МТС ы җитәкчеләре моның белән исәпләшеп тормаганнар. Алар учетчы заправщикка һәр смена саен ике хезмәт көне, ә көнгә 4 хезмәт көне язганнар.

Колхозларның хезмәт көннәрен әрәм-шәрәм итүгә алып бара торган мондый фактларны кайбер башка МТС ларда да күрергә мөмкин. Мәсәлән, Буденный МТС ының 3 нче номерлы трактор бригадасында (бригадиры Гариф Таҗеттинов) ашлык сугуда эшләүче тракторчыга сугылган һәр тонна ашлык өчен 0,30 хезмәт көне урынына 0,40 хезмәт көне язганнар. Актаныш МТС ында пар җирләрен лущит итүдә норманы киметү исәбенә хезмәт көннәрен артык язып килгәннәр. Кызыл Чапчак МТС ында яз көне эшнең беренче көннәрендә тырмалау өчен хезмәт көнен 2 өлеш язуны 2 көн урынына 6 көн буена дәвам иткәннәр. Шуның нәтиҗәсендә 51 хезмәт көне артык язылган.

СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карары нигезендә, яхшы сыйфатлы итеп үтәлгән эш өчен һәр хезмәт көненә трактор бригадасы бригадиры 75 тиен, бригадир ярдәмчесе 50 тиен күләмендә МТС тан премия алырга тиешләр. Кайбер МТС ларда карарның бу пунктын үтәмиләр, бозалар. Балык Бистәсе МТС ында эшнең сыйфаты нинди булуга карамастан, премияне бригадирның да, аның ярдәмчесенең дә барлык хезмәт көннәренә дә түлиләр. МТС җитәкчеләре моңа юл куюлары белән дәүләт акчасын әрәм-шәрәм итүгә юл куюларын, тракторлар белән эшләү бәясен күтәрүгә сәбәпче булуларын онталар, күрәсең.

Байтак кына МТС ларда учетчы заправщикларны сайлап алуга игтибарсыз караш фактлары яшәп килә. Учетчы-заправщикларның бу эшкә хәзерлексез булулары нәтиҗәсендә, еш кына хәлләрдә, хезмәт көннәрен бутау, югалту яисә артык язу фактлары килеп чыга. Мәсәлән, Заинский МТС ында тракторчы Сергеевка 27 нче номерлы учет кагазе буенча 66 урынына 80 хезмәт көне язганнар.

Колхозларның хезмәт көннәренә шушындый игтибарсыз караш күренешләре Тат. Ялтан МТС ында да бар. Мәсәлән, тракторчы Нуждовка 10 нчы номерлы учет кагазе буенча 9 урнына 13 хезмәт көне, 21 нче учет кагазе буенча тракторчы Жеребенковка 31 урнына 47 хезмәт көне язылган.

Югарыда күрсәтелгән фактлар барсы да трактор бригадаларында хезмәт житештерүчәнлеген түбәнәйтүгә, эшнең сыйфатын начарлатуга китерәләр. МТС җитәкчеләре һәм җир органнары работниклары моны бер минутка да исләреннән чыгармаска тиешләр. ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм СССР Совнаркомы карарын тулысынча һәм дөрес үтәү өчен барлык чаралар күрелергә тиеш.

Мамашев.
Агроном-механизатор.

ШАТЛЫКЛЫ ХЕЗМӘТ

Колхоз оештырылганга кадәр безнең авыл крестьяннәре гектарыннан 5—6 центнердан артык уңыш ала алмыйлар иде. Колхоз төзелгәннән соң авылның йөзе танымаслык булып үзгәрде. Ленин исмендәге колхозда хәзер сеялкалар, культиваторлар, катлаулы молотилкалар һәм башка төрле авыл хуҗалыгы машиналары бар. 1937—38 нче елларда колхоз бөртекле культураларның гектарыннан уртача 17,28 центнер уңыш алды. 1939 нчы елда гектарыннан уртача 15 центнер уңыш алды.

Колхозның терлекчелеге дә кызу темплар белән үсә. Колхозда хәзер 3 ферма—товарлыклы сөтчелек, сарык үрчетү һәм дуңгыз үрчетү фермалары бар. Шулай ук 113 баш умарта бар. Колхозның материаль нигезе көннән-көн үсә. Шул ук вакытта колхозчыларның көнкүреш хәле һәм аларның культурасораулары да үсә. Колхоз пар тегермәне, тимерчелек, столярьлык мастерское төзеде, хәзер ашлык салу өчен ике катлы амбар төзү тәмам булып килә. Колхозда шулай ук яңа мәктәп, клуб һәм балалар яслесе дә төзелде. Укыйяза белмәүчелек тулысынча бетерелде.

Колхозчылар хезмәткә социалистик караштa тәрбияләнәләр, алар колхоз байлыгын саклыйлар һәм арттыралар. Хезмәт дисциплинасы нык. Стахановчылар саны арта. Стахановчылардан Биктяскин, Могуков, Золина, Күбряков иптәшләр норманы 200 — 250 процент үтиләр һәм елына 500—600 хезмәт көне эшләп алалар. 1938 нче елны иптәш Могуков хезмәт көннәренә 60 центнер ашлык һәм 962 сум акча, ә иптәш Максим Кудряшев—59 центнер ашлык һәм 945 сум акча алды.

Колхозчылар мул тормышта яшиләр. Һәрбер колхозчының сыеры, вак терлеге, кошлары бар. Колхозчыларның кләтләре төрле продуктлар белән тулы.

Колхоз Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашу хокукын яулап алды. Күргәзмә комитеты колхозны II нче дәрәҗәле диплом, акчалата 5.000 сум бүләк һәм мотоцикл белән бүләкләде. Бу бүләк колхозчыларда зур энтузиазм тудырды. Шушы бүләкне алуга багышланган митингда 65 яшьлек стахановчы колхозчы иптәш Могуков болай диде:

— Колхозчы иптәшләр, тормышыбыз башкача булып әверелде. Караңгылык һәм мохтаҗлык мәңгегә бетерелде. Мин бу яңа тормышка карыйм да, чиктән тыш шатланам. Мондый тормышны безгә кем тәэмин итте? Аны партиябез һәм кадерле остазыбыз иптәш Сталин тәэмин итте. Аңа зур рәхмәт!

Аннары, иптәш Золина сүз алып болай диде:

— Татарстан һәм Башкыртстан арасында төзелгән социалистик ярыш миңа үз эшемдә нык борылыш ясарга ярдәм итте. Быел мин биш дуңгыздан 75 дуңгыз баласы алып үстердем. 1940 нчы елны һәрбер ана дуңгыздан 20 дуңгыз баласы алып үстерергә йөкләмә алам һәм Тельман районындагы барлык терлекчеләрне социалистик ярышка чакырам.

Ленин исмендәге колхоз Бөек Октябрь Социалистик Революциясенең XXII еллыгына барлык авыл хуҗалыгы эшләрен һәм дәүләт алдындагы йөкләмәләрен үтәде. 1940 нчы елгы ит тапшыру планы да 50 процентка үтәлде инде.

Н. Конов.
Тельман районының Ленин исмендәге колхоз председателе.

Тәнкыйть-библиография

Файдалы кулланманың кайбер кимчелекләре

Шушы араларда Татгосиздат башлангыч мәктәпләр өчен „Русча-татарча сүзлек“ басып чыгарды. Сүзлек—7 табак чамасы зурлыкта, җыйнак кына, матур гына, пөхтә генә итеп эшләнгән. Сүзлекне Г. Нугайбәк, профессор Корбангалиев һәм М. Гыймадиев иптәшләр төзегәннәр. Җаваплы редакторлары—Ибрай Газый һәм Гыйльман Вәлидев иптәшләр.

Бу сүзлекне басып чыгаруны Татгосиздатның соңгы вакыттагы уңышлы адымнарыннан берсе дип карарга кирәк. Сүзлеккә гомумән бәя бирүгә килгәндә сүзлекне канәгатьләнерлек дип табарга мөмкин. Шулай да китапның кайбер кимчелекләрен күрсәтми булмый.

Барыннан да элек, ике телдә дә бер үк әйтелә торган һәм бер үк формада языла торган сүзләргә тукталып үтәргә кирәк. Мәсәлән, армия, артист, балкон, башмак, вагон, газ, газета, галстук, география, закон, лампа, председатель, промышленность, пружина, радио, самовар, фабрика, шкаф кебек сүзләр, алар инде безнең телебезгә тәмам үзләшеп, үз сүзебез булып әверелгәннәр. Сүзлеккә аларны кертмәскә дә мөмкин иде. Әгәр шундый сүзләрнең кайберләренә, мәсәлән, аэроклуб, бассейн, вал, вывеска, диктатура, прожектор, экипаж кебек, кайбер укучылар өчен аңлаешсыз, яки аз аңлаешлы, яисә бер яклы гына аңлаешлы (мәсәлән, экипаж) сүзләргә мәгънәләре бирелгән булса иде, ул чагында мондый сүзләрнең сүзлектә урын алуын аклап булыр иде.

Кайбер сүзләрдә исә сүзлекне төзүчеләр икенче бер чиккә ташланганнар: һәрбер балага яхшы таныш булган „адрес“ сүзенә „хатны кая илтергә һәм кемгә тапшырырга икәнен күрсәтеп, конвертка язылган язу“ дип „бик тулы“ аңлатма бирелә. Монда, бер яктан, аңлатма бирү кирәксез булса, икенче яктан, аңлатманың тулы булмавы, укучыны буталдыруга сәбәп була, чөнки адресның конверт тышына языла торган язу гына түгеллеге истән чыгарыла. Кайбер сүзләргә, мәсәлән, башмак, ваза сүзләренә „аяк киеме, савыт“ дип аңлатма бирү белән генә дә эш җайланмый.

Инде сүзләргә тулы тәрҗемәләр бирелмәүгә килик. Сүзлекнең үзендә болай диелгән: „Татарча тәрҗемә өлешендә, русча сүзләрнең башлангыч мәктәп дәреслекләрендә очраган мәгънәләрен генә, сүзләрнең туры мәгънәләрен генә, башлангыч мәктәп балаларының аңына якын торган мәгънәләрен генә бирергә тырышылды“. Бу шулаймы соң? Әле шушы көннәрдә генә Саттарова һәм Арсланова иптәшләрнең „Учебник русского языка для татарской начальной школы“ дигән китаплары басылып чыкты (Татгосиздат, 1939). Шул китаптан, мәсәлән, „цветы“, „ученье“ кебек сүзләрне алып карыйк. „Цветы“ның туры мәгънәсе „гөл“ дә, „чәчәк“ тә була ала, ә сүзлектә „чәчәк“ генә бирелгән. Шулай ук „с новыми силами взялись за ученье“ дигән җөмләдә „ученье“ сүзе турында да шуны ук әйтергә кирәк. Бу җөмләдә ул „уку“ мәгънәсендә килә, сүзлектә исә бу мәгънә бөтенләй юк. Ә ул „ученье“нең туры мәгънәләреннән берсе. Мондый сүзләр бик күп. Балалар аңына якын булган мәгънәләрдән „рәхмәт“ (благодарность), „әһәмиятле“ (важно), „мәсьәлә“ (вопрос), „өтеләү“ (гладить), „аннары“ (дальше), „бурычлы“ (должен), „(күз) йому“ (закрывать), „язылу“ (записаться), „үткен“ (зорко), „мактаулы“ (почетный), „эшләү“ (сделать) кебек мәгънәләр сүзлектә бөтенләй урын алмаганнар. Боларны бик күп китерергә мөмкин. Хәтта „предмет“, „провалиться“ кебек сүзләрнең нак менә укучы балалар аңына якын тора торган мәгънәләре бирелмәгән.

Кайбер сүзләр, әгәр аларны нак сүзлектәге мәгънәләрендә алсаң (ә мәктәп баласының шулай алмый хәле дә юк) көтелмәгән нәтиҗәләргә китерәчәкләр. Мәсәлән, „пострелять“ сүзенә „аткалау“ дип мәгнә бирелгән. Шуның буенча „дай, я постреляю“ дигән җөмләне „бир мин атып карыйм“ диясе урында „бир, мин аткалыйм“ дип аңларга кирәк була. „Потянуть“ сүзе дә шулай ук.

Берничә сүзгә аңлатмада бик саксызлык күрсәтелгән. „Посетить“ сүзенә „бару яки килү“ дип тәрҗемә бирелгән дә, „йомыш белән яки хәл белергә“ дип аңлатма бирелгән. Димәк, музейга һәм күргәзмәгә дә хәл белергә баралар булып чыга!

Сүзлекне төзүчеләр бик тырышып матбугат теленнән качканнар. Укучы балалар газета белән бик кызыксыналар бит. Шулай булгач, аларны газета теле белән таныштыруны беренче бурычларның берсе итеп куярга кирәк иде. Ә сүзлекнең татарча өлешендә газета сүзләрен табу бик кыен. Мәсәлән, анда „большевистик“, „беседа ясау“, „кукуруэсыз“, „борт“, „көчле“ (бурные аплодисменты) „терлекчелек“, „комсомолец“, „край“, „кухня“ (фабрика-кухня), „килешмәүчән“, „орденлы“, „утрак“, „сайлап алу“ (подбирать), „кабызу“ (поджигатели войны), „яшрен“ (подпольная организация), „полководец“, „положение“ (сайлаулар турында), „правление“ (колхоз правлениесе), „работник“, „данлыклы“, „удар“, „ашлык“ (хлеб) кебек бик күп сүзләр юк.

Сүзлектә кайбер сүзләргә ялгыш, ә кайберләренә тупас мәгънәләр бирелгән. Мәсәлән, „бурлак“ сүзенә „электә Волга буенда ялланып эшләүче эшче“ дигән мәгнә бирелгән. Бу дөрес түгел. Волга буенда һәрбер ялланып эшләгән эшче бурлак дип аталмаган. „Гирлянда“ны „юан бау“ дип атаганнар. Бауны чәчәкләрдән яки агач ботакларыннан үрмиләр! „Единоличник“ сүзенә „аерым хуҗалыкчы“ дип тәрҗемә бирелгән. Бу да дөрес түгел. Бу сүзнең билгеләнгән термины бар: „Ялгыз хуҗалыкчы“. Аңа инде яңа термин уйлап чыгаруның һич кирәге юк. Мондый сүзләрне дә күп китерергә мөмкин.

Ниһаять, татар телендә бөтенләй кулланылмый торган, яки кайбер аерым урыннарда, аерым кешеләрдә генә кулланыла торган сүзләр күп кертелгән: „комар“ (азарт), „бута“ (верблюжонок), „шарлама“ әдәбиятка кергән „шарлавык“ водопад] урнына), „сыкы“ (иней), „тапинамбур“ (клубень), „хат букчасы“ (конверт), „чос“ (меткий) „әсрәйтү“ (насторожить), „кугын“ (погоня), „әрәкә“ (рак), „кырыс“ (строгий).

Китапның ахрында бирелгән 6 төзәтмәдән тыш китапта тагын 10 урында типография ялгышлары калган.

Шулай итеп, чибәр генә, файдалы кулланманың дәрәҗәсе, әһәмияте нык кына төшерелгән.

Төхфәт.

„ҮРНӘК“ КОЛХОЗЫНДА

Октябрь районының „Үрнәк“ колхозы членнары язгы чәчүгә зур оешканлык белән хәзерләнәләр. Чәчү орлыкларын чистарту һәм кар тоту чаралары үткәрү күптән тәгалләнде. Басуга 570 йөк тирес чыгарылды. Урындагы ашламаларны җыю эше дә уңышлы бара. Машиналарга һәм инвентарьга ремонт ясау 50 процент үтәлде. Бу эштә тимерче иптәш Ильин норманы 130 процент үтәп бара.

Колхозчылар агротехниканы өйрәнү түгәрәгенә актив катнашалар. Түгәрәккә 30 кеше тартылган.

В. Ислам.

Чит илләрдә

ЕВРОПА СУГЫШЫ

Сугыш хәрәкәтләре турында Германия хәбәре

БЕРЛИН, 3 гыйнвар. (ТАСС). Сугыш хәрәкәтләре турында Германия информация бюросының белдерүендә болай диелә:

„Мозель белән Пфальц урманы арасында дошман Германия позицияләренең алдынгы линиясенә җиңелчә ут ачты. Рейндә Германиянең хәрби частьләре урнашкан кайбер урыннарга дошман пулеметтан һәм танкка каршы пушкалардан атты. Германия ягыннан шунда ук каршы ут ачылды. Мерциг янында Германиянең 7 самолеты белән дошманның 12 самолеты арасында булган кечкенә генә сугыш вактында бер машина да бәреп төшерелмәде. Чик янында берничә пунктта Германиянең истребительләр авиациясе һәм һава һөҗүменә каршы оборонасы хәрәкәт итте. Алар дошман авиациясенең һөҗүменә тоткарлык ясадылар. Германиянең Франция өстендә очышлар ясаган берничә разведка самолеты французларның һава оборонасы хәрәкәте сферасыннан кача алдылар.

Англия командованиесенең раславына караганда, Англиянең кичә Төньяк диңгез өстендә Германиянең „Миссершмитт“ самолетларына каршы сугышкан 3 бомбардировщигының берсе үзенең базасына кайткан, имеш. Ләкин Англиянең Виккерс-Веллингтон бомбардировщикларының 3 сенең дә бәреп төшерелгәнлеге ачык маглүм булганлыктан, биредә сүз Германия истребительләренә очрамыйча Англиягә исән-сау кайткан 4 нче бомбардировщик туры нда бара torгандыр дип уйларга мөмкин. Һава сугышында Германия ягыннан, Англиянең информация министрлеге раслаганча 12 самолет түгел, бәлки 4 кенә самолет катнашты. Англия информация министрлеге дошманның сан ягынкан артык булуын сылтау итмәкче булган булса кирәк“.

ЗИГФРИД ЛИНИЯСЕ НИЧЕК ТӨЗЕЛДЕ

„Дейче альгемейне цейтунг“ газетасы Германия инженеры Пехлингерның көнбатышта Германия ныгытмаларын төзүгә багышланган китабыннан өзекләр басып чыгарды. Автор, төзү эшләренең зур булуы һәм аларны үтәү срогының кыска булуы аркасында күп кенә махсус чаралар үткәрергә кирәк булганлыкны күрсәтә.

Бөтен көнбатыш чик 22 участкыга бүленгән. Зигфрид линиясен төзүдә барлыгы 1.000 чамасы фирма катнашкан.

Махсус төзү бюросында ике ай буена 60 меңнән артык план һәм чертеж хәзерләнгән. Бик күп миллионнарча кубометр бетон һәм башка төрле материаллар кирәк булган. Германиянең цемент промышленносты Зигфрид линиясе өчен көне-төне эшләгән һәм үзенең бөтен продукциясенең 51 процентын шушы төзелеш өчен генә биргән. Көн саен 45 мең кубометр бетон хәзерләнгән.

1938 нче елның 20 нче июнендә төзелешкә беренче 9.000 кеше килгән. 13 нче июльгә эшчеләр саны 20.000 кешегә, 21 нче сентябрьгә—241 мең кешегә җиткән. Болардан тыш сапер частьләреннән 90 мең кеше һәм хезмәт повинносты үтүчеләрдән 300 чамасы отряд тартылган. Гомумән төзелештә ярты миллионнан артык кеше эшләгән.

Төзелешне кирәкле материаллар белән тәэмин итү өчен анда көн саен 9.000 вагон килеп торган. 1938 нче елның сентябрендә төзелештә 16 мең чамасы автомашина эшләгән. Тимер юлга артык күп эш йөкләмәү өчен Рейн елгасы пароходларыннан киң файдаланылган. Эшчеләрне тору урыннарыннан төзелешкә һәм кире өйләренә ташу өчен 4.200 автобус кирәк булган.

Төзелеш кызу темплар белән баруга да карамастан, эшнең сыйфатына аеруча игтибар бирелгән. Зигфрид линиясе гаять күп санда зур һәм кечкенә ныгытмалардан тора. Бу ныгытмалар бөтен урында корылганнар. Барлыгы 22 мең бетонлы точкалар төзелгән, шул исәптән броняле авыр корылмалар ясалган. Алар Германиянең көнбатыш чигендә Бодензеедән Рейннең Голландиягә чыга торган урнына кадәр сузылалар. Линиянең озынлыгы 600 километр, киңлеге 50 километрдан артык. Сугыш башланганнан соң Зигфрид линиясе Голландия чиге буйлап Төньяк диңгезгә кадәр сузылды. Хәзер аның гомуми озынлыгы 850 километр һәм ул Альптан алып диңгезгә кадәр Германиянең бөтен көнбатыш чиген саклый.

3 гыйнвар. (ТАСС).

Сугышның беренче 4 ае эчендә Англиянең һәм Франциянең югалтулары

Венгриядә чыга торган „Пестер Ллойд“ газетасы Англия-Франция сугыш блогының сугыш иглан ителгәннән бирле булган югалтулары турында хәбәр итә. Газета болай дип яза:

„Югалтулар турында Англия-Франция тарафыннан бергәләп иглан ителгән исемлек буенча 30 нчы ноябрьгә кадәр 1.433 француз һәм 2.511 англичан үтерелгән.

Англиянең коры җир армиясенең шушы вакыт эчендә бары 3 кешесе генә үтерелгән. Алар бәхетсезлек вакыйгасы нәтиҗәсендә һәлак булганнар. Англиянең хәрби диңгез флотында 2.070 кеше, ә авиациясендә 438 кеше үтерелгән.

Франциянең коры җир армиясендә 1.136 кеше үтерелгән, Франциянең хәрби диңгез флотында—255 кеше, ә хәрби һава флотында—42 кеше үтерелгән“.

4 гыйнвар. (ТАСС).

ҺИНДСТАН МИЛЛИ КОНГРЕССЫНЫҢ РЕЗОЛЮЦИЯСЕ

КАБУЛ, 3 гыйнвар. (ТАСС). Һиндстанда чыга торган „Бомбей кроникл“ газетасы, Һиндстан милли конгрессы бюросының резолюция кабул иткәнлеген хәбәр итә. Резолюциядә болай диелә: „Конгресс вәкилләре Һиндстанның бәйсезлеген җиңел генә яулап алырга мөмкин түгеллекне беләләр. Хәзер конгресс көчләү методлары ягында түгел, ләкин ул гражданнарның каршылык күрсәтүен яклый, чөнки ул бәйсезлек өчен көрәш методларының берсе“.

Канада профсоюзлары конгрессы председателенең мөраҗәгате

НЬЮ-ЙОРК, 3 гыйнвар. (ТАСС). Канада профсоюзлары конгрессы председателе Мур яңа ел уңае белән профсоюз члennарына карата чыгарган мөраҗәгатендә Канада эшчеләренең социаль реформалар үткәрү өчен һәм гражданлык хокукларын саклап калу өчен көрәшне дәвам иттерергә тиешлекләрен белдергән.

Кытайдагы сугы" хәрәкәтләренә карата. РӘСЕМДӘ: Кытай хатын-кызларыннан төзелгән хәрби госпиталь медицина сестралары.

Р. Кармин фотосы (ТАСС фото-клишесе).

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Кантоннан төньяк-көнчыгышта сугышлар дәвам итә. Сицзян елгасы белән тимер юл арасындагы күп кенә пунктлардан кытай гаскәрләрен японнарның кысрыклап чыгарырга маташулары уңышсыз чыкты. Шулай ук Цунхуа, Лянкоу һәм Лунмынь районнарында да сугышлар дәвам итә. Өстәмә нығытмалар килү белән 31 нче декабрьдә кытай гаскәрләре японнарның Лунмынь секторындагы позицияләренә һөҗүм башладылар. 2 нче гыйнварда японнар көньякка таба чигенә башладылар.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Вэньси—Сясяньнән көнчыгыштарак (Шаньси провинциясенең көньяк өлешендә), кытай гаскәрләре японнарның позицияләренә атака ясадылар һәм берничә урында шоссе юлын җимерделәр.

Әлегә тикшерелмәгән маглүматларга караганда, 31 нче декабрьдә японнарның көчле рәвештә көн буена һавадан бомбага тотуларыннан соң, кытай гаскәрләре Баотоуны (Суйюань провинциясе) яңадан ташлап чыгарга мәҗбүр булганнар.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Соңгы көннәрдә Туншань районында (Хубэй провинциясенең көньяк өлешендә), каты сугышлар булды һәм кытай гаскәрләре күп кенә пунктлардан японнарны куып чыгардылар.

Иоцзякоу секторында (Ханькоудан көнбатышка таба) кытайлар японнарның барлык атакаларын кире кактылар. Ханькоудан төньяк-көнбатышта япон гаскәрләре танклар, артиллерия һәм авиация ярдәме белән кытайларның Хань елгасының көньчыгыш ярындагы позицияләренә көчле басым ясыйлар.

1 нче гыйнварда, Ханань провинциясенең көньяк өлешендә кытай истребительләре японнарның „Небесный ветер“ типындагы разведка самолетын бәреп төшерделәр. Бу самолет Япония разведка самолетларының соңгы моделе буенча эшләнгән булган.

30 нчы декабрьдә японнар Мэнцзы янында французлар карамагындагы Ханой—Кунь—Мин тимер юлын бомбага тотканнар. 31 нче декабрьдә японнарның җиде самолеты Ичанга (Хубэй провинциясе) налет ясаганнар һәм Америка миссионерлары миссиясе дворына бомбалар ташлаганнар. Дүрт эшче үтерелгән.

КЫТАЙНЫҢ 4 НЧЕ АРМИЯСЕНЕҢ ҺӘМ ПАРТИЗАННАРНЫҢ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ШАНХАЙ, 3 гыйнвар. (ТАСС). „Чайна пресс“ газетасы болай дип хәбәр итә: „Шанхай—Нанкин—Ханчжоу өчпочмагында яхшы хәзерлекләре булган 100.000 чамасы сугышчыдан тора торган кытай армиясе хәрәкәт итә. Алар Янцзы елгасының көньягындагы барлык районнарда Цзянси провинциясендә һәм Ханчжоу заливыннан төньякта хәрәкәт итәләр. Бәрелешләрнең күпчелеге Ханчжоу, Цзясин һәм Хучжоу арасындагы чама белән 35 мең квадрат миль булган секторда үткәрелгән. Монда японнарның 10.000 дән артык солдаты үтерелгән“.

Газетаның хәбәр итүенә караганда, Ханчжоу заливында урнашкан Хайянь шәһәре өчен аеруча каты сугышлар булган. Үткән елны ул 6 тапкыр кулдан-кулга күчеп торган иде.

„Үткән елны партизан отрядлары бу районда япон гаскәрләренә һәм курчак хөкүмәт отрядларына каршы кимендә 200 зур сугыш алып бардылар. Японнарның юллары 300 тапкырдан артык җимерелгән. 50 ләп тимер юл һәм шоссе күпере җимерелгән. Партизаннар японнарның 100 ләп сугыш катерларын, бронемашиналарын, шулай ук җиңел һәм йөк автомобильләрен алганнар.

Үткән елның апрель башында кытай партизаннарының күп санлы отряды Ханчжоу—Нанкин юлының көньяк участкысындагы Укан шәһәрен чолгап алганнар. Шуннан соң Шанхай—Ханчжоу тимер юлына партизаннарның атакалары башланган. Атакалар нәтиҗәсендә бу юлда хәбәрләшү кимендә 10 тапкыр өзелгән.

4 нче армия махсус өйрәнү өчен тылга күп санлы командирлар җибәргән. Алар партизаннар хәрәкәтенә җитәкчелек итү өчен тулысынча хәзерлекле булып кайтканнар һәм японнарга каршы сугышларга уңышлы җитәкчелек иткәннәр. Партизаннар һәм 4 нче армия еш кына японнарның азык складларын һәм йөкләрен басып алалар“.

ТӨРКИЯДӘ СТИХИЯ ҺӘЛАКӘТЛӘРЕ

ПАРИЖ, 3 гыйнвар. (ТАСС). Гавас агентлыгы, кичә көннең икенче яртысында Иозгад районында шактый көчтә җир астыннан яңадан тетрәүләр ишетелгәнлеген хәбәр итә. Шәһәрдә һәм аның тирәләрендә 184 йорт җимерелгән. Халык арасындагы корбаннар турында әлегә маглүматлар юк.

Бер үк вакытта башланып киткән көчле яңгырлар уңае белән көнбатыш Анатоли районнарында су басудан шәһәр хуҗалыгына шактый зыян килгәнлеге хәбәр ителә. Балыкиҗерда, Бурсада, Измитта һәм Адапазарыда су басудан 336 йорт һәм күп санда күперләр җимерелгән.

В. В. Куйбышев исемендәге Финанс-Экономика институты студентларыннан Т. Травина, С. Демкин һәм А. Маринов иптәшләр хәрби кабинетта пулемет частьләрен өйрәнәләр.

В. Мясников фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

ЭКЗАМЕННАР БАШЛАНДЫ

Казан Дәүләт Медицина институтында 1 нче гыйнвардан кышкы экзаменнар сессиясе башланды. Экзаменнарның беренче көне студентларның сессиягә нык хәзерләнгәнлекләрен күрсәтте. Дәвалау-профилактика факультетының 207 нче группасы нормаль анатомия буенча экзамен тапшырды. Группадагы 24 студенттан 12 кеше „отлично“ һәм 6 кеше „яхшы“ билгеләре алдылар. 204 нче группа студентларының да күпчелеге анатомия буенча „яхшы“ һәм „отлично“ билгеләре алдылар.

Марксизм-ленинизм нигезләре фәне буенча булган экзаменнар студентларның бу фәнне аеруча яхшы үзләштерүләрен күрсәтәләр. Бу, аеруча IV—V нче курсларда укучы студентларга туры килә.

Салих Камал.

КЫСКА ХӘБӘРЛӘР

— Ширәмәт районы Ширәмәт авылында яңа елга 400 урынлы яңа мәктәп ачылды. Мәктәп төзелеше 183 мең сумга төште.

„Выгороженный ключ“ авыл хуҗалыгы артеленең колхоз умартачылыгы 1939 нчы елда 1.000 потка якын бал алды. Һәрбер хезмәт көненә 500 грамм бал туры килә. Колхозчы З. Маслов семьясе 1.500 хезмәт көненә 40 поттан артык, Гурьянов һәм В. Маслов семьяләре һәр кайсы 35 әр пот бал алдылар.

— 1939 нчы елның декабрь аенда Казан гармон фабрикасы планнан тыш 240 гармон, 3 баян һәм 2 аккордеон эшләп чыгарды.

— Красный Бор районы Исәнбай авылында 35 койкалы яңа төзелгән больница ачылды. Больница төзү эшенә 200 мең сумнан артык акча тотылды. Больницаның бала тудыру бүлеге һәм гомуми бүлеге бар.

— Апас районы Шонгаты авылындагы Сталин исемендәге колхоз янында 10 кешедән торган охотниклар бригадасы оештырылды. Бу бригадага охотник-отличник иптәш Захаров җитәкчелек итә. Быелгы сезонда бригада 250 куян, 10 төлке, 2 бүре тотты инде. (ТатТАСС).

В. И. Ленингә багышланган марш

„Батыршин маршы“ н язган һәвәскәр-композитор Габидулла иптәш Мәҗитев пролетариатның бөек даһие Владимир Ильич Лениннең үлүенә 16 ел тулуга багышлап яңа траур маршы язды. Марш шагыйр Әхмәт Исхакның „Ильич“ дигән шигыренә язылды. Мәҗитевнең „Ильич маршы“ на композитор иптәш Виноградов гармонизация ясады. Марш шушы көннәрдә басылып чыгачак.

Композитор иптәш Мәҗитев бу марштан тыш 1939 нчы елда татар совет шагыйрьләренең шигырьләренә унга якын көй язды. Алар арасында М. Гатау сүзләренә язылган „Сталин турында җыр“, М. Садри сүзләренә „Совет Ватаны өчен“, орденлы шагыйр Ш. Маннур сүзләренә „Туй җыры“, Нур Гайсиннең лирик шигыренә „Сөю“, музыкаль сюэтә һәм башкалар бар. Хәзер иптәш Мәҗитев Ш. Маннурның Октябрьгә багышлап язылган шигыренә музыка язарга керешге.

Татарстан Сәламәтлек Саклау Халык Комиссариаты физкультура эшеннән читтә тора

1940 нчы елның 1 нче гыйнварыннан ГТО ның яңа комплексы тормышка ашырыла башлады. СССР Халык Комиссарлары Советы үзенең 1939 нчы ел 26 нчы ноябрь карары белән күп кенә наркоматларны бу эшне тормышка ашыруда булышлык күрсәтергә мәҗбүр итте. Сәламәтлек саклау халык комиссариатларына спорт-физкультура белән шөгыльләнүчеләр өстеннән тәртипле рәвештә медицина күзәтүе алып бару, шулай ук ГТО комплексы буенча норма тапшыручыларны медицина смотрлары аша үткәрү бурычлары йөкләтелде. Кызганычка каршы, Татарстан Сәламәтлек Саклау Халык Комиссариаты тарафыннан бу бурыч тиешенчә үтәлми. Казанда соңгы елларда медицина смотрларының бөтенләй булганы юк. Кайчандыр Казанда физкультура үзәк йорты бар иде. Бу йорт физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләрне медицина смотрлары аша үткәрә һәм фәнни-тикшеренү эшләре белән шөгыльләнә иде. Хәзер бу йорт кабинет булып кына калды. Кабинетның бары тик 1—2 кешелек штаты бар. Ул көндезге 2 сәгаттән генә эшли башлый. Аннан соң кабинет медицина институтының тулай торагында урнашкан булганлыктан, аңа керүе дә кыен. Шуңа күрә күп кенә физкультурниклар медицина смотрларын үзләренең эшли торган җирләрендә, яки поликлиникаларда үтәләр. Монда шуны да әйтергә кирәк, күп кенә врачлар физкультура һәм спорт сораулары белән таныш түгелләр. Кайбер врачлар аерым физкультурникларга авыр атлетика белән шөгелләнергә ярамый, җиңел атлетика белән генә шөгыльләнергә мөмкин дигән киңәшне бирәләр. Ләкин бу бөтенләй үк дөрес түгел. Җиңел атлетикадагы кайбер хәрәкәтләр авыр атлетикага караганда да кыенрак. Мәсәлән, 3.000—5.000 метр дистанциягә йөгерү авыр әйбер күтәрүгә караганда шактый кыен.

Казан шәһәрендә физкультура врачлары 5—6 кеше генә исәпләнә. Ә аларга сорау гаять зур. Районнарда бу эш аеруча начар тора. Физкультура эшенә медицина хезмәте күрсәтү белән берәү дә шөгыльләнми. Татарстан Сәламәтлек Саклау Халык Комиссариатының шушы көнгә кадәр бу җаваплы участкыны онытуы бик аяныч. Физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләр өстеннән һич шиксез медицина һәм санитария күзәтүе булдырылырга тиеш.

Физкультурникларга медицина хезмәте күрсәтүне тамрыннан яхшырту өчен физкультура һәм спорт белән шөгыльләнүчеләрнең сәламәтлекләрен һәр вакыт күзәтеп торырга кирәк. Шулай ук физкультура-врачлык кадрларын хәзерләү һәм врачлык-күзәтү кабинетларын арттыру буенча да уйларга кирәк. БГТО һәм ГТО значокларына норма тапшыручыларга хезмәт күрсәтү районнарда поликлиника врачлары һәм фельдшерлар көче белән үткәрелергә тиеш. Моның өчен Татарстан Сәламәтлек Саклау Халык Комиссариаты физкультурникларга медицина хезмәте күрсәтү мәсьәләсе буенча семинарлар үткәрергә тиеш.

А. Иевлев, Д. Федотов.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Автоуправлениенең
бензин һәм майлау материаллары конторасы
шәһәрдәге һәм районнардагы бензин алучыларның кулларындагы
ТАЛОННАРНЫ ТЕРКӘҮ ҮТКӘРӘ
Шәһәрдәге бензин алучыларның талоннарын теркәү шушы ел 8 нче гыйнварга, ә районнардагы бензин алучыларның талоннарын теркәү 13 нче гыйнварга кадәр дәвам итә.
Бензин һәм майлау материаллары станциясенең Автотранспорт наркоматына күчерелүе уңае белән, күрсәтелгән срокта теркәлмәгән талоннар гамәлдән чыккан дип исәпләнәчәк.
Бензин талоннарын теркәтергә килүчеләрдән ышаныч кәгазе сорала.
5—3—1

ТАТАРСТАН АССР НАРКОМПРОСЫ ЯНЫНДАГЫ
ЧИТТӘН ТОРЫП УКУ ЗУРЛАР МӘКТӘБЕ
5, 6, 7, 8, 9 ҺӘМ 10 нчы КЛАССЛАРГА
УКУЧЫЛАР АЛА
Мәктәп производстводан аерылмыйча үзлегеннән уку юлы белән, тулы булмаган урта һәм урта мәктәп программалары буенча экстерн рәвештә экзамен бирү өчен хәзерләнергә мөмкинлек бирә. Мәктәпкә 16 дан түбән булмаган яштәге кешеләр алыналар.
Читтән торып укучыларга ярдәмгә группалы һәм индивидуаль консультацияләр оештырыла. Уку кирәк-яраклары бирелә.
Гаризалар һәр көн эш сәгатьләрендә 1940 нчы ел 1 нче февральгә кадәр алына.
Гариза белән бергә, керүченең белеме турында документ, хезмәте урныннан белешмә һәм кабул ителгән үрнәктәге анкета бирелергә тиеш.
Читтән торып уку мәктәбенә керүчеләрдән—5 нче класска керүчеләр рус теленнән һәм арифметикадан, ә башка классларга керүчеләр шул класстан түбәнге классның программасы буенча барлык предметлардан сынаулар үтәләр.
Мәктәптә укудан тукталган кешеләр, укудан тукталуга 3 елдан артык булмаса, сынаусыз алыналар.
Сынаулар 1 нче февральдән, ә укулар 20 нче февральдән башлана.
Адрес: Казан, Кремль, Татнаркомпрос, 5 нче бүлмә. Телефон: Кремль, 22.
Татарстан АССР районнарында торучылар гаризаларны Арча, Әгерҗе, Аксубай, Акташ, Этнә, Акташ, Бөгелмә, Буа, Кукмара, Куйбышев, Лаеш, Мамадыш, Норлат, Минзәлә, Мөслим, Чаллы, Алабуга, Тәтеш, Шөгер һәм Чистай районара консультация пунктларына (урта мәктәпләр янында) бирәләр.
Тулы маглүматларны РОНО дан алырга мөмкин.
Дирекция.
2697—3—1

25 нче гыйнвар, кич 5 сәгатьтә Казан Дәүләт Ветеринария институтының актовый залында институт гыйлми советының ачык утырышы чакырыла һәм ветеринария фәннәре докторы дигән гыйлми дәрәҗә алу өчен Троицкий ветеринария институты доценты В. В. Никольский тарафыннан халык алдында
ДИССЕРТАЦИЯ ЯКЛАУ
үткәрелә
Тема: „Йорт куяннары пастереллезын экспериментал өйрәнү буенча материаллар“.
Рәсми оппонентлар: профессор доктор М. В. Рево, профессор Н. М. Верещагин һәм фәннәр кандидаты доценты Ф. З. Амфитеатров.
Диссертация материаллары белән институт көтепханәсендә танышырга мөмкин.
10—1

ӨЛКӘ ҺӘМ ҮЗӘК
ЖУРНАЛЛАРГА
1940 нчы ел өчен
ПОДПИСКАЛАР АЛУ
шушы ел 10 нчы
гыйнварга кадәр
ДӘВАМ ИТӘ
18—1 „СОЮЗПЕЧАТЬ“.

1939 нчы елның 30 нчы декабреннән Татарстан АССР Биектау районы үзәгендә
дәүләт банкысының Биектау район бүлеге ачылды.
МФО № 3166.
Б—1

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
5 нче гыйнварда һәм 6 нчы гыйнварда кич, шулай ук 7 һәм 8 нче гыйнварда премьера
КЫЮ КЫЗЛАР
Бүген талон 88.
6 нчы гыйнварда көндез
КҮЗЛӘР
Талон 89.
Спектакль кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
5 нче һәм 6 нчы гыйнварда көндез һәм кич
ПАВЕЛ ГРЕКОВ
Талоннар: бүген 69, иртәгә көндез 15, кич 70.
Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 8 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.
КАНИКУЛ КӨННӘРЕНДӘ
6, 9 һәм 12 нче гыйнварда көндезге спектакльләргә коллектив заявкалар буенча килүчеләргә (100 билеттан ким булмаганда) 50 процент ташлама ясала.

Киров районындагы
Культура сарае
5 нче гыйнварда
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
Талон 39.
Спектакль кич сәгат 8 дә башлана.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Тулысынча яңа программа
Москва 4 нче труппасының гастрольләре.
ЯҢА ЕЛ КАРНАВАЛЫ
Бөтен труппа катнаша.
Орденлы АЛЛИ-ВАД ның һәм ВЕРА МИРОВАНЫҢ соңгы гастрольләре.
12 нче гыйнварга кадәр һәр көн 11 сәгатьтә, 2 сәгат 30 минутта һәм кич 8 дә
ЦИРК УЕННАРЫ
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

1939 нчы ел 16 нчы декабрьдә 13 яшьлек ир бала югалды. Баланың исеме Миңлегаяз һәм фамилиясе Хәернасов. Ул турыда белүчеләнең түбәндәге адрес буенча белдерүләре сорала: Татарстан АССР, Кукмара районы, Купка авылы, Хәернас Закиров. 2—1

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЕЛЕКТРО“ 10, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Көндез 10 сәгатьтә ХӘЗИНӘЛӘР АТАВЫ һәм башка сеансларда ПАРТБИЛЕТ
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	ДУСЛАР ЯҢАДАН ОЧРАШАЛАР Көндез 10 сәгатьтә балалар өчен сеанс
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 11, 1, 3, 5, 7-30 һәм 10 да	Көндезге сеансларда АЛТЫН АЧКЫЧ Кич БӨЕК ГРАЖДАНИН (икенче сериясе)
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	ЦИРК
„ПИОНЕР“ 6, 8 һәм 10 да	Көндез һәм кич ҺАВА ПОЧТАСЫ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкәчә тәрбия яшендәге балалар өчен сеанс ВАРЯ КАПИТАН
„РОТ-ФРОНТ“ 10, 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	СОРОЧИНСКАЯ ЯРМАРКА
„КОЛХОЗНИК“ 6, 8 һәм 10 да	БАЛТЫЙКЧЫЛАР
КУЛЬТУРА САРАЕ 5. 7 һәм 9 да.	СЕНТЯБРЬДӘГЕ ТӨН

Казан Күн сбруйлар фабрикасы
М—1 маркалы
җиңел һәм йөк автомашиналары сатып ала
Казан, Ягодный бистәсе, Краснококшай урамы, 39. Телефон 43—72.
2541—2—2

ЭНЕРГОСБЫТ
абонентларына
белдерә:
50 киловаттан югары көчле трансформаторлары булган промышленность предприятиеләре 1940 нчы елда электр һәм елылык энергиясе алу өчен 1940 нчы ел 7 нче гыйнварга кадәр договор язарга тиешләр. Белешмәләр алу өчен—Татарстан урамы, 14 адресы буенча яисә 12—23 һәм 17—81 телефоннары буенча мөраҗәгат итәргә. 2668—2—1

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 2475. ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА ДОМ ПЕЧАТИ. 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 63.